КАЗАНСКИЙ ФЕДЕРАЛЬНЫЙ УНИВЕРСИТЕТ


ИНСТИТУТ ФИЛОЛОГИИ И МЕЖКУЛЬТУРНОЙ КОММУНИКАЦИИ

*Кафедра татарского языка и методики преподавания*

**Хадиева Гульфия Камиловна**

# Татар теле фонетикасы

## Лекцияләрнең конспекты



**Казань – 2014**

**Направление подготовки:** 45.03.01 «Филология» (академический бакалавр, 1 курс (1 семестр), очное обучение). Профиль: Прикладная филология: татарский язык и литература, журналистика. Прикладная филология: татарский язык и литература, переводоведение с углублённым изучением иностранного языка. Прикладная филология: татарский язык и литература, информационные технологии с углублённым изучением иностранного языка.

**Учебный план:** Подготовка бакалавров (2014, очное).

**Шифр и название дисциплины:** Б 1. Б. 14.1 «Фонетика татарского языка».

**Количество часов:** бакалавр - 81 ч. (в том числе: лекции – 26, практические занятия – 28, самостоятельная работа – 27); форма контроля – экзамен.

**Аннотация:** “Татар теле фонетикасы” курсыннан тәкъдим ителә торган кулланманың максаты – студентларның татар теле фонетикасы буенча алган белемнәрен тирәнәйтү, аларның мөстәкыйль эшләрен оештырырга юнәлеш бирү.

Бу курста төп игътибар сөйләм аппаратын, авазларның ясалышын күзаллау, аларны төрле яклап тасвирлау, татар сөйләменә хас фонетик үзенчәлекләр, басым, интонация, аваз һәм хәреф, дөрес язу, дөрес әйтү темаларына юнәлтелә.

**Темы**: 1. Хәзерге татар әдәби теленең фонетик системасы. Сөйләм авазларын өйрәнү аспектлары. Татар теле фонетикасын өйрәнү тарихы. 2. Татар теленең авазлар системасы. Сузык авазлар. Дифтонглар. 3. Тартык авазлар. 4. Татар телендә фонетик закончалыклар. Аваз үзгәрешләре. Авазларның комбинатор үзгәрешләре. 5. Авазларның позицион үзгәрешләре. 6. Сөйләмнең фонетик кисәкләргә бүленеше. Иҗек. Басым. Интонация. 7. Графика һәм орфография. 8. Орфоэпия

**Ключевые слова**: *хәзерге татар әдәби теле, сузык авазлар, тартык авазлар, комбинатор аваз үзгәрешләре, позицион аваз үзгәрешләре,*

*ассимиляция, аккомодация, диссимиляция, орфография, орфоэпия, иҗек, басым, интонация.*

**Дата начала использования**: 1 сентября 2014 г

**Автор - составитель:** Хадиева Гульфия Камиловна, кандидат филологических наук, доцент кафедры татарского языка и методики преподавания Института филологии и межкультурной коммуникации К(П)ФУ, e-mail: gul-khadieva@yandex.ru

**Тәкъдим ителгән курсның электрон версиясе бар:** http://bars.kfy-elearning.ru/course/view.php?id=1499

**Эчтәлек**

Тема 1. Хәзерге татар әдәби теленең фонетик системасы. Сөйләм авазларын өйрәнү аспектлары. Татар теле фонетикасын өйрәнү тарихы..........................................................................................5

Тема 2. Татар теленең авазлар системасы. Сузык авазлар. Дифтонглар...................................................................................17

Тема 3. Тартык авазлар..................................................................22

Тема 4. Татар телендә фонетик закончалыклар. Аваз үзгәрешләре. Авазларның комбинатор үзгәрешләре 26

Тема 5. Авазларның позицион үзгәрешләре.......................................33

Тема 6. Сөйләмнең фонетик кисәкләргә бүленеше. Иҗек. Басым. Интонация............................................................................................36

Тема 7. Графика һәм орфография .......................................................42

Тема 8. Орфоэпия...............................................................................47

Глоссарий 52

Тәкъдим ителә торган информацион чыганаклар.............................59

Тәкъдим ителә торган электрон ресурслар.......................................65

“Татар теле фонетикасы” курсыннан имтихан сораулары...................................................................................66

Белемнәрне гомумиләштереп кабатлау өчен тестлар.......................69

## Тема 1. Хәзерге татар әдәби теленең фонетик системасы. Сөйләм авазларын өйрәнү аспектлары. Татар теле фонетикасын өйрәнү тарихы

**Аннотация.** Фонетиканың өйрәнү объекты, бурычлары билгеләнә. Аваз һәм фонема турында мәгълүмат, сөйләм авазларын өйрәнү аспеклары һәм татар теле фонетикасын йрәнү тарихы яктыртыла.

**Терәк сүзләр.** Фонетика, фонема, аваз, сегмент берәмлекләр, суперсегмент берәмлекләр, артикуляцион аспект, физик аспект, лингвистик аспект.

**Методик тәкъдимнәр.** Тема буенча гомуми күзаллау бирелә. Аны өйрәнергә һәм сорауларга җавап бирергә кирәк.

**Тәкъдим ителә торган информацион чыганаклар:**

**Төп әдәбият**


1. *Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З.* Хәзерге татар әдәби теле: Югары һәм урта уку йортлары өчен дәреслек. Тулыл. 2 нче басма. – Казан: Мәгариф, 2002. – 235-241 б. (Алга таба: *Сафиуллина, Зәкиев,* 2002)

2. *Сәлимов Х.Х.* Татар теле фонетикасы. – Чаллы: Камаз нәшр., 1993. – 31 б.

3. *Татар грамматикасы.* Өч томда. Т. I. / Ред. колл. М.З. Зәкиев, Ф.Ә. Ганиев, К.З. Зиннатуллина. – Мәскәү: Инсан; Казан: Фикер, 1998. – 61-151 б. (Алга таба: *Татар грамматикасы* Т. I, 1998)

4. *Хәкимҗан Ф.* Татар әдәби теле: Фонетика. Югары уку йортлары студентлары өчен. – Тулылан. 2 нче басма. – Казан: ТДГИ, 2001. – 108 б. (Алга таба: *Хәкимҗан,* 2001)

5. *Хисамова Ф.М.* Хәзерге татар теле фонетикасы. Татар филологиясе бүлеге студентлары өчен методик күрсәтмәләр. – Казан, 1987. – 44 б. (Алга таба: *Хисамова,* 1987)


**Өстәмә әдәбият**


1. *Алпаров Г.* Шәкли нигездә татар грамматикасы. – Казан, 1925; 2-басма. – Казан, 1926. – 164 б.

2. *Афлетунов А.Ш.* Фонетика современного татарского языка: Методические указания для студентов заочников по изучению курса и выполнению контрольных работ. – Казань, 1962. – 53 с.

3. *Байчура Ү.Ш.* Татар теленең кайбер фонетик үзенчәлекләре (Эксперименталь-фонетик мәгълүматлар буенча) // Татар теле һәм әдәбияты мәсьәләләре. – Казан, 1963. –127-140 б.

4. *Бакеева Д.Х.* Сопоставительная фонетика английского и татарского языков. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1985. – 141 с.

5. *Бакиров М.Х.* Закономерности тюркского и татарского стихосложения в свете экспериментальных исследований. – Казань: АКД, 1972. – 298 с.

6. *Богородицкий В.А.* Фонетика татарского языка в связи с другими тюркскими языками. – Вестник научн. общ-ва татароведения. - №4. – Казан, 1926. – С. 92-93.

7. *Богородицкий В.А.* Этюды по татарскому и тюркскому языкознанию. – Казань: Татиздат, 1933. – 156 с.

8. *Богородицкий В.А.* Введение в татарское языкознание в связи с другими тюркскими языками. Под. ред. чл.-кор. АН СССР проф. Н.К. Дмитриева. – 2-е изд., испр. и доп. – Казань: Татгосиздат, 1953. – 220 с.

9. *Вәлиди Җ.* Татар теленең кагыйдәләре. – Казан, 1918. – 44 б.

10. *Вәлиева В.С., Саттаров Г.Ф.* Урта мәктәп һәм гимназияләрдә татар телен укыту методикасы. – Казан: “Раннур”, 2000. – 95-143 б.

11. *Газизов Р.С.* Сопоставительная грамматика татарского и русского языков. – Казань: Таткнигоиздат, 1966. – 368 с.; Казан, 1977. – 271 с.

12. *Ганиев Ф.А.* Фонетическое словообразование в татарском языке. – Казань: Тат. книж. изд-во, 1973.

13. *Гиганов И.* Грамматика татарского языка. – СПб., 1801.

14. *Җәләй Л.* Татар теленең тарихи фонетикасы буенча материаллар. – Казан: Таткнигоиздат, 1954. – 108 б.

15. *Зиндер Л.Р.* Общая фонетика. – Л.: Изд-во Ленинград. ун-та, 1960; М.: Высшая школа, 1979.

16. *Исследования по сравнительной грамматике тюркских языков:* Фонетика. Ч. I.– М.: изд. АН СССР, 1955.

17. *Камчатнов, А*. М. Введение в языкознание [Электронный ресурс] : учеб. пособие / А. М. Камчатнов, Н. А. Николина. - 10-е изд., стереотип. - М. : Флинта:Наука, 2011. - 232 с. // http://znanium.com/bookread.php?book=405795

18. *Лингвистические задачи*: Учебное пособие / Б.Ю. Норман. - М.: Флинта: Наука, 2006. - 272 с. // http://znanium.com/bookread.php?book=320773

19. *Махмудов Г.* Практическое руководство к изучению татарского языка. – Казань, 1858.

20. *Миргалимова З.Ф., Сәләхетдинова З.Ф.* Татар теле: Фонетика. Югары уку йорты студентлары өчен уку-укыту кулланмасы. – Казан: Редакционно-издательский центр, 2011. – 119 б.

21. *Насыри К.* Краткая татарская грамматика. – Казань, 1860.

22. *Насыйри К.* Әнмүзәҗ. – Казан, 1895; Казан, 1975. – 213 б.

23. *Нуриева Ф.Ш.* Атрибуция языка письменных памятников Золотоордынского периода. – Астана: “Кантана Пресс”, 2011. – 180 с.

24. *Сабиров К.С.* Фонетик ысул белән сүз ясалышы // Совет мәктәбе. – 1970, – №5 – 35 б.

25. *Сайхунов М.Р.* Ритмо-темпоральные характеристики татарского языка в плане автоматического синтеза в речи: Автореф. дис. …канд. филол. наук. – Казань, 2010. – 26 с.

26. *Саттаров Г.Ф.* Фонетика укытуга карата // Совет мәктәбе. – 1964. – №9. – 37-39 б.

27. *Саттаров Г.Ф.* Сопоставительный анализ звукового состава татарского литературного языка и диалектов // Вопросы татарского языкознания. – 1965. – С. 120-146.

28. *Сафиуллина Ф.С.* Хәзерге татар әдәби теле фонетикасы: Күнегүләр җыентыгы. – Казан, 1968. – 43 б.

29. *Сафиуллин Ф.С.* Тел гыйлеменә кереш. – Казан: “ТаРИХ”, 2001. – 37-104 б.

30. *Сафиуллина Ф.С.* Хәзерге татар әдәби теле: Күнегүләр. Югары һәм урта уку йортлары өчен тулыландырылган икенче басма. – Казан: Мәгариф, 2002. – 5-27 б.

31. *Сәгыйтов М.А.* Фонология, аның идея һәм проблемалары. – Казан: Казан пед. инс-ты нәшр., 1972. – 120 б.

32. *Сөнгатов Г.М.* Татар диалектларының фонетикасы: Татар филологиясе һәм тарихы факультеты студентлары өчен уку ярдәмлеге. – Казан: КГУ, 2000. – 44 б.

33. *Сөнгатов Г.М.* Татар теленең фонетик закончалыклары: Теоретик мәгълүмат, күнегүләр һәм биремнәр. – Казан: КГУ, 2001.–53б.

34. *Сунгатов Г.М.* Фонетическая система заболотного говора тоболо-иртышского диалекта сибирских татар (экспериментально – фонетическое исследование): Автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Казань, 1991. – 23.

35. *Сунгатов Г.М.* Экспериментально-фонетическое исследование татарской диалектной речи. – Казань: Сиддхи-секьюрити, 2002. – 108 с.

36. *Теория языка*. Вводный курс: Учебное пособие / А. А. Горбачевский. - М.: Флинта: Наука, 2011. - 280 с. // http://znanium.com/bookread.php?book=447873

37. *Хаков В.Х.* Татар әдәби теле тарихы. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1993. – 325 б.

38. *Хаков В.Х.* Тел тарих көзгесе (Татар әдәби теленең үсеш тарихыннан). – Казан: Татар. Кит. нәшр., 2003. – 295 б.

39. *Халфин И.* Азбука и грамматика татарского языка. – Казань, 1809. – 106 с.

40. *Халфин С.* Азбука татарского языка с обстоятельным описанием букв и складов. М., 1778; М.: Издательство МГУ; Издательство КГТУ, 1996. – 60 с.

41. *Хәзерге татар әдәби теле:* Лексика, фонетика, орфоэпия, графика һәм орфография, морфология: Югары уку йорты студ. һәм урта мәктәп укытучылары өчен. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1965. – 96-176 б.

42. *Шакирова Р.Ф.* Хәзерге татар теле фонетикасына кереш. – Казан: Таткнигоиздат, 1954. – 104 б.

43. *Юсупов Ф.Ю.* Җирле сөйләш шартларында фонетика укыту. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1977. – 165 б.

44. *Юсупов Ф.Ю.* Көньяк Урал һәм Урал арты сөйләшләре: Чиләбе һәм Курган өлкәләрендәге татар сөйләшләренең фонетик үзенчәлекләре. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1979. – 184 б.

45. *Яфаров Л.И.* Татар теле фонетикасының кайбер закончалыклы тенденцияләре: Филол. фән. канд. ... дисс. – Казан, 1955. – 264 б.

46. *Яфаров Л.* Татар теле үсештә. – Казан: Татгосиздат, 1955. – 130 б.

47. *Radloff W.W.* Phonetik der nordlichen Turksprachen. – Leipzig, 1883.

**Тәкъдим ителә торган электрон ресурслар:**

www.wikipedia.ru  Универсальная энциклопедия «Википедия»

www.ksu.ruЭлектронная библиотека и материалы сайта КПФУ

www.slovari.ru  Электронные словари

**Глоссарий**

**Аваз** – сөйләмнең таркалмый торган иң кечкенә берәмлеге.

**Актив органнар** – артикуляция процессында хәрәкәтләнә торган органнар. Мәсәлән, тел, йомшак аңкау, иреннәр, тавыш ярылары, үпкәләр.

**Акустик аспект (физик аспект)** – авазларны өйрәнүнең бер аспекты, авазларны физик күренеш буларак, тавыш дулкыннарының тирбәнеше дип карау.

**Гомуми фонетика** – төрле телләр өчен уртак булган аваз һәм фонема, аваз үзгәрешләре, авазларны төркемләү, иҗек, басым, сөйләмнең фонетик кисәкләргә бүленешенең теоретик мәсьәләләрен хәл итә.

**Сегмент берәмлекләр –** билгеле бер эзлеклелектә килә торган авазлар. Шул авазлар тезмәсе икенче бер сегмент берәмлекне – иҗекне формалаштыра

**Синтаксик фонетика** – сөйләмнең фонетик кисәкләрен, басым һәм интонацияне тикшерә.

**Сөйләм аппараты** – кешенең сөйләм барлыкка китерә торган әгъзалары җыелмасы.

**Суперсегмент берәмлекләр** – аваз һәм иҗекләрдән зуррак булган сүз һәм фразаны характерлаучы берәмлекләр.

**Тарихи фонетика** – конкрет бер телдәге аваз системасының төрле чорлар дәвамындагы үсеш-үзгәрешен тикшерә.

**Тасвирлама фонетика** – аерым бер телнең билгеле бер үсеш этабындагы авазлар системасын тасвирлау, аларның яшәешен өйрәнү белән шөгыльләнә.

**Фонема** – телдәге сүзләрне һәм морфемаларны төзи, аларны бер-берсеннән аерырга ярдәм иткән аваз системасының иң кечкенә берәмлеге. Татар телендә - 12 сузык, 28 тартык фонема бар.

**Фонетика** – тел белеменең бер бүлеге, ул авазларны, аларның кушылмаларын, аваз үзгәрешләрен өйрәнә.

**Чагыштырма фонетика** – чит һәм туган телдәге авазларны чагыштырып өйрәнә.

**Эксперименталь фонетика** – авазларның ишетелеш һәм әйтелеш ягын төрле техник чаралар, төгәл аппаратура ярдәмендә өйрәнә.

**Сораулар:**

1. Фонетиканың өйрәнү объекты һәм бурычлары.
2. Фонетиканың өйрәнү максатына карап төрләре.
4. Сегмент һәм суперсегмент берәмлекләр турында төшенчә.
3. Аваз һәм фонема турында төшенчә.
4. Сөйләм аппаратының төзелешен әйтегез.

5. Л.В. Щербаның фонема һәм фонема вариантларына биргән билгеләмәсе.

6. Авазларның өйрәнелү аспекты.

7. Татар теле фонетикасын өйрәнү тарихы.

Кешене төрле тавышлар чолгап алган: кошлар сайравы, агачлар шаулавы, машина моторы тавышы, этләр өрүе... Бары тик сөйләм авазлары гына сүзләр ясый. Алар дөньяны чолгап алган предметларны, күренешләрне атыйлар.

Сөйләм авазлардан тора. Авазлар сүзнең мәгънәсен аеруда катнаша. Тел белеменең Фонетика (грек. *phonetike; phone* – “аваз”, *tike* – “караган”,“бәйле”)– телдәге авазларны, аларга хас булган закончалыклы күренешләрне өйрәнә. Ул әдәби телдә дөрес сөйләү, сөйләм культурасы, туган телне укыту, чит телләр укытуда кирәк. Шулай ук, фонетиканы өйрәнү кешеләр сөйләменең дөреслеген, төгәллеген аңларга, шулай ук дөрес язарга, орфографик кагыйдәләрне төшенергә ярдәм итә.

Фонетиканың өйрәнү максатына карап төрләре:

Хосусый фонетика – аерым бер телнең аваз ягын тикшерә; ул акустик, артикулятор, функциональ фонетикага бүленә.

Гомуми фонетика – төрле телләр өчен уртак булган аваз һәм фонема, аваз үзгәрешләре, авазларны төркемләү, иҗек, басым, сөйләмнең фонетик кисәкләргә бүленешенең теоретик мәсьәләләрен хәл итә.

Тасвирлама фонетика – аерым бер телнең билгеле бер үсеш этабындагы авазлар системасын тасвирлау, аларның яшәешен өйрәнү белән шөгыльләнә.

Тарихи фонетика – конкрет бер телдәге аваз системасының төрле чорлар дәвамындагы үсеш-үзгәрешен тикшерә; авазларның тарихи үзгәрешен, законлы аваз тәңгәллекләрен, аваз үзгәрешләренең сәбәпләрен өйрәнә.

Эксперименталь фонетика – авазларның ишетелеш һәм әйтелеш ягын төрле техник чаралар, төгәл аппаратура ярдәмендә өйрәнә.

Чагыштырма фонетика – чит һәм туган телдәге авазларны чагыштырып өйрәнә.

Синтаксик фонетика – сөйләмнең фонетик кисәкләрен, басым, интонацияне тикшерә.

**Тоташ сөйләмнең бүленеше**

**Сегмент берәмлекләр:** аваз, иҗек

**Суперсегмент берәмлекләр:** иҗек, басым, интонация; бу берәмлекләр сөйләм авазларыннан башка яши алмый

Аваз – сөйләмнең таркалмый торган иң кечкенә берәмлеге.

Фонема – телдәге сүзләрне һәм морфемаларны төзи торган, аларны бер-берсеннән аеру өчен хезмәт итә торган иң кечкенә аваз берәмлеге.

Хәзерге татар телендә 12 сузык, 28 тартык фонема бар:

| Сузык авазлар | Тартык авазлар |
|---|---|
| [а] [ә] [у] [ү] [о][ө] [ы] [э] [и] [ō] [ы] [э] | [б] [п] [в] [w] [м] [ф] [д] [т] [н] [ң] [с] [з] [х] [һ] [ч] [ш] [щ] [ж] [җ] [л] [р] [й] [к] [қ] [г] [ғ] [ц] [ء] |

Л.В. Щерба “Фонетика французского языка” (1963) дигән хезмәтендә фонеманың табигатен түбәндәгечә аңлата:

“...җанлы сөйләмдә без уйлаганнан күбрәк төрле авазлар ишетелә, бу авазлар һәр аерым телдә чагыштырмача азрак сандагы аваз типларына

берләшә. Алар мәгънә аеруда катнашалар һәм шул рәвешле кешеләрнең аралашуларына хезмәт итәләр... Без аларны *фонема* дип... бер үк фонеманың һәр аерым очракта әйтелә торган төрләрен *фонема вариантлары* дип атарбыз".

Авазларның өйрәнелү аспекты:

1. Артикуляцион (физиологик, биологик) аспект.
2. Физик (акустик) аспект.
3. Лингвистик (иҗтимагый, фонологик, функциональ) аспект.

Артикуляцион аспект, авазлар кеше организмының бер функциясе буларак тикшереләләр, авазларны әйтүдә сөйләм органнарының (үпкәләр, тын юлы, бугаз, тавыш ярылары, йоткылык, тел, кече тел, иреннәр, тешләр, каты һәм йомшак аңкау, авыз, борын, тамак куышлыгы) кайсылары һәм ничек катнашулары карала.


Авазлар сөйләм органнары ярдәмендә ясала. Бу органнар сөйләм аппараты дип атала.

Авазлар ясалуда бугаз төп рольне уйный. Бугазда мускул җепселләре бар. Алар тавыш ярылары дип атала. Авазларны әйткәндә тавыш ярылары ачыла да, ябыла да. Шуның белән бәйле рәвештә, үпкәләрдән килгән һава агымы тавыш һәм шау барлыкка китерә.

Сузык авазларны әйткәндә һава агымы авыз куышлыгында бернинди тоткарлыкка очрамый, шуңа күрә аларны сузып була. Сузык авазлар тавыштан гына торалар.

Тартык авазларны әйткәндә, һава агымы авыз куышлыгында тоткарлыкка очрый. Алар тавыштан һәм шаудан яки шаудан гына торалар.

Сөйләм аппаратының схемасы. I – авыз куышлыгы; II – йоткылык (фаринкс); III – борын куышлыгы; IV– бугаз куышлыгы.




1) йоткылык өсте; 2) өске ирен; 3) өске тешләр; 4) альвеолалар; 5) каты аңкау; 6) йомшак аңкау; 7) кече тел; 8) аскы ирен; 9) аскы тешләр; 10) тел алды өлеше; 11) телнең уртасы; 12) тел арты; 13) тел төбе; 14) бугаз өсте; 15) чүмечсыман кимерчәк; 16) тавыш ярылары арасындагы тавыш ярыгы; 17) калкансыман кимерчәк; 18) балдаксыман кимерчәк; 19) трахея; 20) үңәч; 21) балдаксыман кимерчәк.

Физик аспект, авазлар табигатьтәге бер физик күренеш буларак, һава дулкыннарының тирбәнеше буларак тикшереләләр. Аларның озынлыклары, көче, югарылыгы, тембры яки спектры характерлана.

Лингвистик аспекттан авазлар телдә сүзләрне һәм морфемаларны төзүче, аларны бер-береннән аерырга мөмкинлек бирүче иң кечкенә аваз берәмлекләре, фонемалар буларак өйрәнелә.

Татар фонетикасының өйрәнелү тарихы.

Татар теле фонетикасына караган беренче мәгълүматлар XVIII-XIX йөзләрдә басылган дәреслекләрдә чагылыш тапканнар. Бу дәреслекләр барысы да укыту максатларыннан язылганнар, Аларда төп игътибар русларга татар теле грамматикасын өйрәтүгә юнәлгән була. Грамматикаларга әлифба

өйрәтүгә бәйле рәвештә фонетика бүлеге дә кертелә. Бу дәреслекләрдә аваз һәм хәреф аерылмаган була, татар телендә өч сузык барлыгы әйтелә.

XX йөз башында чыккан дәреслекләрнең фонетикага кагылышлы бүлекләрендә авазлар төркемләнә. К.Насыйри, Ш.Таһири, Г.Нугайбәк, М.Корбангалиев һ.б. татар телендә 10 сузык аваз барлыгын әйтәләр, Һ.Максуди Г.Ибраһимов, Ш.Әхмәдиев һ.б. татар телендә 6 сузык булганлыгын яклаганнар.

Фонетика буенча беренче мәгълүматларны С. Хәлфиннең 1778 нче елда басылган “Азбука татарского языка с обстоятельным описанием букв и складов” исемле әлифбасыннан табарга була. К. Насыйри авазларга классификация ясый, татар телендә ун сузык фонема булуын әйтә. В.В.Радловның “Төньяк төрки телләр фонетикасы” дигән хезмәте төрки телләрнең аваз төзелешен чагыштырып өйрәнү өлкәсендә зур әһәмияткә ия була. Анда татар фонетикасының бик күп мәсьәләләре тикшерелә: татар теленең авазлары башка төрки телләр белән чагыштырып бирелә, кайбер авазларның кулланылыш закончалыклары ачыклана, сингарманизм һәм басым мәсьәләләре тикшерелә. В.В.Радлов татар телендә 11 сузык, 23 тартык аваз саный.

Г. Алпаровның 1926 нчы елда басылган “Шәкли нигездә татар грамматикасы” хезмәтендә татар авазлары фәнни нигездә характерлана.

В.А. Богородицкий, Казанда Россиядәге иң беренче экспериментал фонетика лабораториясен оештыра, татар теле буенча экспериментал-фонетик тикшеренүләр үткәрә. Сүзләрдәге тон хәрәкәтен тасвирлый, авазларның озынлыгын, көчен тикшерә.

В.А.Богородицкийның идеяләрен аның шәкерте Г.Шәрәф дәвам итә. Ул авазларның артикуляция үзенчәлекләрен тикшерә; кимографик язмаларның графикларына таянып, төрле фонетик позицияләрдә авазларның озынлыклары ничек үзгәрүен билгели, басымның һәм иҗек төренең аваз озынлыгына тәэсирен ачыклый.

Р.Ф.Шакированың “Хәзерге татар теле фонетикасына кереш” (1954) хезмәте татар теленең авазларын тасвирлаган беренче монографик хезмәт булып тора. Биредә беренче тапкыр авазлар фонологик яктан карала башлыйлар, аваз үзгәрешләренең төрләре билгеләнә, интонациянең кайбер мәсьәләләре яктыртыла, татар телендә 12 сузык фонема булуын әйтә.

Ү.Байчура “Татар теленең аваз төзелеше” хезмәтендә фонемаларны аерып алу критерийлары бирелә, шулар нигезендә фонемалар составы ачыклана; рентген сурәтләре һәм палятограммалар ярдәмендә вокализм һәм консонантизм сурәтләнә; эксперименталь мәгълүматларга нигезләнеп , татар авазлары чуваш, хакас, казах һ.б. телләрнең авазлары белән чагыштырыла; аваз үзгәрешләре, тартыкларның акустик билгеләре, сүз басымының үзенчәлекләре кебек мәсьәләләр карала; хезмәт ахырында рентгенограммалар, палатограммалар, кимограммалар, таблицалар, схемалар рәвешендә бай иллюстратив материал бирелә.

1970 нче еллардан башлап татар теле фонетикасы буенча хезмәтләр Х.Х.Сәлимов эшчәнлеге белән бәйләнгән. Ул спектраль анализ методын кулланып, татар вокализмын тикшерә, татар сузыкларын акустик яктан тасвирлый, аваз үзгәрешләренең төрләрен ачыклый; автор тарафыннан татар теленең беренче орфоэпик сүзлеге төзелә, мәктәпләр һәм югары уку йортлары өчен фонетика буенча кулланмалар языла.

Татар теленең тарихи фонетикасы буенча Л.Җәләй башлаган тикшерүләрне Л.И. Яфаров, В.Х. Хаков, Ф.М. Хисамова, Ф.Ш. Нуриева һ.б. дәвам итә.

Диалекталь фонетика буенча кызыклы күзәтүләр А.Бессонов, Г.Ахмаров, Л.Җәләй, Д.Г. Тумашева, Л.Т. Мәхмүтова, Г.Ф. Саттаров, Ф.Ю. Юсупов, Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, Н.Б. Борһанова, Г.М. Сөнгатов һ.б. тарафыннан ясала.

Татар теленең графикасы, орфографиясе, орфоэпиясе мәсьәләләре Л.Җәләй, Х.Р. Курбатов, Б.М. Мифтахов, Р.А. Юсупов, Р.С. Абдуллина, И.М. Низамов, Г.С. Нуриев һ.б. хезмәтләрендә яктыртыла.

Татар фонетикасы хәзерге заман лингвистикасының казанышларына һәм бай традицияләренә таянып үсә бара.

**Белемнәрне тикшерү өчен сораулар.**

1. Фонетика нәрсәне өйрәнә?

2. Фонетиканың өйрәнү максатына карап нинди төрләре бар?

3.Фонетиканы өйрәнүнең теоретик һәм гамәли әһәмиятен билгеләгез.

4. Сөйләм авазлары нинди аспектлардан чыгып өйрәнелә?

5. Авазларның нинди акустик билгеләре бар? Алар нинди берәмлекләр белән үлчәнәләр?

6. Сөйләм аппаратының төзелешен әйтегез.

7. Сөйләм авазы һәм фонема арасында нинди уртаклык һәм аерма бар?

8. Л.В. Щербаның фонема һәм фонема вариантларына биргән билгеләмәсен яттан әйтегез.

9. Фонетикада нинди тикшеренү ысуллары кулланыла?

10. Татар теле фонетикасын өйрәнгән галимнәрне һәм аларның хезмәтләрен әйтегез.

## Тема 2. Татар теленең авазлар системасы. Сузык авазлар. Дифтонглар.

**Аннотация.** Татар телендәге сузык фонемаларның саны, составы турында мәгълүмат бирелә. Сузык авазларга характеристика китерелә. Форманта, дифтонглар турында мәгълүмат бирелә.

**Терәк сүзләр.** Сузык авазлар, форманта, дифференциаль билге, алгы рәт сузыклар, арткы рәт сузыклар, вокализм, дифтонг.

**Методик тәкъдимнәр.** Тема буенча гомуми күзаллау бирелә. Аны өйрәнергә һәм сорауларга җавап бирергә кирәк.

**Тәкъдим ителә торган информацион чыганаклар:**

**Төп әдәбият**

1. *Сафиуллина, Зәкиев,* 2002. – 185-193 б.

2. *Сәлимов Х.Х.* Татар теленең сузык авазлары. – Куйбышев, 1989. – 80б.

3. *Татар грамматикасы* Т. I, 1998. – 64-79 б.

4. *Хәкимҗан,* 2001. – 24-37 б.

5. *Хисамова,* 1987. – 8-17 б.

**Өстәмә әдәбият**

1. *Байчура У.Ш.* Звуковой строй татарского языка. – Ч.I. – Казань: Изд-во КУ, 1959. – С. 24-61.

2. *Исхаков Ф.Г.* Характеристика отдельных гласных современных тюркских языков // Исследования по сравнительной грамматике тюркских языков. – Ч. I. Фонетика. – М.: Изд-во АН СССР, 1955. – С. 53-114.

3. *Исхаков Ф.Г.* Об отдельных фонемах татарского языка // Исследования по сравнительной грамматике тюркских языков. – Ч.I. Фонетика. – М.: Изд-во АН СССР, 1955. – С. 218-238.

4. *Салимов Х.Х.* Спектральный анализ татарских гласных: Автореф. дис. ...канд. филол. наук. – Казань, 1975. – 24 с.

5. *Саттаров Г.Ф.* Алынма сузыкларны өйрәнү // Совет мәктәбе. – 1966. - №10. – 32-35 б.

6. *Сәлимов Х.Х.* Хәзерге татар теле фонетикасы. Методик күрсәтмәләр. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1978. – 65 б.

7. *Фасеев Ф.С.* Вокализм татарского языка в синхронии и диахронии // К формированию языка татар Поволжья и Приуралья. – Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова, 1985. – С. 99-109.

8. *Харисова Ч.М.* Татар теле: Теория, күнегүләр, тестлар. – Казан: “Мәгариф”, 2006. – 7-30 б.

9. *Хәкимҗан Ф.* Татар әдәби теле фонетикасы: Күнегүләр җыентыгы. – 2000. – 28 б.

10. *Шараф Г.* Сонорная длительность татарских гласных // Вестник научного общества татароведения. - Казань, 1928. - №8. – С.180-265.

11. *Шараф Г.* Палятограммы звуков татарского языка сравнительно с русскими. – Казань, 1927. – 40 с.

**Тәкъдим ителә торган электрон ресурслар:**

www.wikipedia.ru Универсальная энциклопедия «Википедия»

www.ksu.ruЭлектронная библиотека и материалы сайта КПФУ

www.slovari.ru Электронные словари

**Глоссарий**

**Алгы рәт сузыклар** – авыз куышлыгының алгы өлешендә ясала торган сузыклар, ягъни нечкә сузыклар.

**Арткы рәт сузыклар** – авыз куышлыгының арткы өлешендә ясала торган сузыклар, ягъни калын сузыклар.

**Вокализм** – телнең сузык авазлар системасы. Сузык авазларның билгеләре һәм алар арасындагы мөнәсәбәтләр.

**Нечкә сузыклар** – алгы рәт сузыклары, авыз куышлыгының алгы өлешендә ясала торган сузыклар.

**Озын сузыклар** – артикуляцияләре бердәй һәм бер-берсеннән бары яңгырау озынлыгы белән генә аерыла торган сузыклар.

**Рәт** – сузык авазларны әйткәндә, телнең горизанталь юнәлештәге торышы. Сузыклар алгы рәт, арткы рәт сузыкларына бүленәләр.

**Сузык авазлар** – акустик яктан тавыштан гына торалар, әйткәндә һава агымының сөйләм аппараты аша тоткарлыксыз үтеп китүе нәтиҗәсендә ясалалар, иҗек төзиләр.

**Сораулар:**

1. Татар телендә сузык авазлар.

2. Сузыкларны төркемләү.

3. Формантаның әһәмияте.

4. Сузыкларның дифференциаль билгесе

5. күтәрелмә һәм төшерелмә дифтонглар.

Татар теленең авазлар системасы. Сузык авазлар. Сузык авазларны төркемләү. Авазлар сузыкларга һәм тартыкларга бүленәләр. Сузыклар һәм тартыклар арасында өч аерма бар:

- артикуляцион аерма: сузыкларны әйткәндә, үпкәдән килә торган һава агымы тоткарлыксыз үтә; тартыкларны әйткәндә, сөйләм аппаратының берәр урынында каршылыкка очрый, һава агымы көчлерәк тә була.
- акустик аерма: сузыклар тавыштан, гармоник һава тирбәнешләреннән торалар, тартыкларны әйткәндә шау да катнаша.
- лингвистик аерма: сузыклар иҗек ясаучы авазлар, тартыклар үзләре генә иҗек ясый алмыйлар.

Хәзерге татар әдәби телендә 12 сузык аваз бар. Шуларның тугызы – татар теленең үз сүзләрендә, өч аваз рус теленнән кергән алынма сүзләрдә кулланыла.

Артикуляцион яктан, әйтелешләре буенчасузыклар түбәндәгечә төркемләнә:

1) телнең горизонталь хәрәкәтенә мөнәсәбәтле рәвештә татар сузыклары алгы рәт [ә] [э] [ө] [ү] [и] [э¯] һәм арткы рәт [а] [ы] [о] [у] [ы¯] [ō] сузыкларына бүленә.

2) Телнең вертикаль хәрәкәтенә мөнәсәбәтле рәвештә сузыклар югары [у] [ү] [и] [ы¯], урта [о] [ө] [ы] [э] [ō] [э¯], түбән [а] [ә] күтәрелеш сузыкларына бүленәләр.

3) Авазларны әйткән вакытта иреннәрнең катнашу-катнашмауларына карап, сузыклар иренләшкән [у] [ү] [о] [ө] [ō] һәм иренләшмәгән [а] [ә] [и] [э] [ы] [ы¯] [э¯] сузыкларга бүленәләр.

Акустик яктан, яңгырашлары ягыннан, микъдари озынлыкка карап, сузыклар чагыштырмача кыска [о] [ө] [ы] [э] һәм чагыштырмача озын [а] [ә] [у] [ү] [и] [ы¯] [э¯] [ō] сузыкларга бүленәләр.

Сузык авазларның формантасы:

Форманта – авыз һәм тамак резонаторлары аша үткәндә көчәеп киткән тавыш тирбәнешләре. Сузык авазларны аера торган иң мөһим акустик билге. Фонетика өчен аеруча беренче ике форманта әһәмиятле, чөнки алар турыдан-туры авазларның артикуляцияләре белән бәйле булалар.

Дифференциаль билге – берәр фонеманы башкаларына каршы куя, башкаларыннан аера торган билге. Мәсәлән, яңгыраулык-саңгыраулык, озынлык-кыскалык һ.б.

Дифтонг – ике сузык авазның бер иҗектә килүе. *Чын дифтонглар* инглиз, алман телләренә, ә *ялган дифтонглар* татар һәм рус телләренә хас. Сузык аваз белән [й] яки [w] тартыкларының кушылмаларын ялган дифтонг дип атыйлар. Ике төре бар: *күтәрелмә* (башта ярымсузык [й] яки [w] тартык авазы килә: йа, йу, wa һ.б.); *төшерелмә* (башта сузык аваз килә: ай, әй, әw һ.б.)

**Белемнәрне тикшерү өчен сораулар**

1. Татар телендә ничә сузык аваз бар? Сузык фонемаларның саны, составы турында татар тел белемендә булган карашлар. К.Насыйри, Г.Алпаров, Р.Ф. Шакирова, Ә.Ш. Әфләтунов, Х.Х. Сәлимов, Ф.М. Хисамова, Ф.Хәкимҗанов һ.б.)

2. Сузыкларны төркемләү принципларын әйтегез.

3. Артикуляцион яктан сузыклар нинди төркемнәргә бүленә?

4. Сузыкларны акустик яктан төркемләгәндә нинди билгеләре искә алына?

5. Нәрсә ул форманта? Лингвистика өчен кайсы форманталар әһәмиятле?

6. Татар телендә беренче формантасы иң югары ешлыкларда урнашкан авазны әйтегез. Беренче формантаның шундый булуы нәрсәгә бәйле?

7. Татар телендә икенче формантасы иң югары ешлыкларда урнашкан авазны әйтегез. Икенче формантаның шундый булуы нәрсәгә бәйле?

8. Нәрсә ул дифференциаль билге? Татар телендә бер генә дифференциаль билге белән аерылган нинди сузык фонемалар бар?

9. Нәрсә ул дифтонг? Татар телендә дифтонглар нинди төрләргә бүленә?

10. Ни өчен *ый* мөстәкыйль фонема дип санала алмый?

## Тема 3. Тартык авазлар

**Аннотация.** Татар телендәге тартык авазларның саны, составы турында мәгълүмат һәм тартык авазларга характеристика бирелә.

**Терәк сүзләр.** Тартык авазлар, яңгырау тартыклар, саңгырау тартыклар, консонантизм.

**Методик тәкъдимнәр.** Тема буенча гомуми күзаллау бирелә. Аны өйрәнергә һәм сорауларга җавап бирергә кирәк.

**Тәкъдим ителә торган информацион чыганаклар:**

**Төп әдәбият**

1. *Сафиуллина, Зәкиев,* 2002. – 194-201 б.

2. *Татар грамматикасы* Т. I, 1998. – 64-79 б.

3. *Хәкимҗан,* 2001. – 37-55 б.

4. *Хисамова,* 1987. – 17-27 б.

**Өстәмә әдәбият**

1. *Байчура У.Ш.* Звуковой строй татарского языка. – Ч.I. – Казань: Изд-во КУ, 1959. – С. 103-139.

2. *Исхаков Ф.Г.* Об отдельных фонемах татарского языка // Исследования по сравнительной грамматике тюркских языков. – Ч.I. Фонетика. – М.: Изд-во АН СССР, 1955. – С. 239-247.

3. *Шакирова Р.Ф.* Хәзерге татар теле фонетикасына кереш. – Казан: Таткнигоиздат, 1954. – 57-71 б.

4. *Щербак А.М.* Сравнительная фонетика тюркских языков. – Л.: Наука, 1970. – 204 с.

**Тәкъдим ителә торган электрон ресурслар:**

www.wikipedia.ru Универсальная энциклопедия «Википедия»

www.ksu.ruЭлектронная библиотека и материалы сайта КПФУ

www.slovari.ru Электронные словари

**Глоссарий**

**Каты аңкау** – авыз куышлыгының өске алгы өлеше. Кайбер авазларны әйткәндә катнаша торган пассив сөйләм органы.

**Кнаклаут** – бугаз тартыгы (һәмзә).

**Консонантизм** – телнең тартыклар системасы, тартыкларның үзенчәлекләре һәм үзара мөнәсәбәтләре.

**Лабио-денталь** – ирен-теш тартыклары.

**Ларингаль** – бугаз тартыгы (һәмзә тартыгы).

**Увуляр тартык** – кече тел тартыгы.

**Фарингаль тартык** – йоткылык тартыгы.

**Фрикатив** - өрелмәле.

**Һәмзә** - бугаз тартыгы.

**Сораулар:**

1. Татар телендә тартык фонемаларның саны.
2. Ясалу урынына карап тартыклар төркемләү.
3. Ясалу урынына карап тартыклар төркемләү.

4. Яңгырау һәм саңгырау тартыклар.

Артикуляция ягыннан тартыклар:

Артикуляцион яктан тартык авазлар түбәндәгечә төркемләнәләр:

- ясалу урыны буенча: үпкәдән килүче һава агымына тоткарлык ясалган урынга карап: ирен-ирен [б] [п] [w] [м], ирен-теш [ф] [в], тел алды [д] [т] [ц] [с] [ч] [щ] [ш] [з] [ж] [җ] [н] [л] [р], тел уртасы [й], тел арты [к] [г], кече тел (увуляр) [қ][ғ] [х] [ң], йоткылык (фарингаль) [h], бугаз (ларингаль) [ء].

- ясалу ысулы буенча: , һава агымына тоткарлыкның ни рәвешле ясалуына карап, йомык [б] [п] [д] [т] [ц] [г] [к] [қ] [ء], өрелмәле [ф] [в] [с] [ч] [ш] [щ] [з] [ж] [җ] [й] [х] [h] [ғ] [w], ярымйомык [м] [н] [л] [ң], калтыраулы [р].


Яңгырау тартыклар тавыш һәм шау катнашында ясала. Саңгырау тартыклар шаудан тора.

Тартык авазның яңгырау яки саңгырау икәнен бик җиңел белеп була. Учыңны бугазга куеп, яңгырау һәм саңгырау тартыкларны әйтеп кара. Яңгырау авазларны әйткәндә, тавыш ярыларының калтыравын, тирбәнешен тоясың, ә саңгырау авазларны әйткәндә, тавыш ярылары калтырамый.

[м], [н], [ң] авазларын әйткәндә, һава агымы борын аша чыга. Шуңа алар борын тартыклары дип атала. Ә калган авазлар авыз тартыклары була.

Акустик яктан тавыш һәм шауның катнашу дәрәҗәсенә карап тартыклар:

**Тартыклар**




Саңгырау тартыклар – артикуляция вакытында тавыш ярылары хәрәкәтләнми, шунлыктан тавыштан башка, шау ярдәмендә генә әйтелә торган тартык авазлар.

Яңгырау тартыклар – артикуляция вакытында тавыш ярылары тирбәлеп, тавыш өстәлеп әйтелә торган тартык авазлар.

Татар теленең кайбер үзенчәлекле авазлары.

Калын сузыклы сүзләрдә каты [къ], [гъ] тартыклары әйтелә: *[акъыл], [гъорур]*. Алар ясалганда, кече тел белән телнең арткы өлеше якыная. Шуңа күрә, [къ], [гъ] – кече тел тартыклары дип атала.

Нечкә сузыклы сүзләрдә йомшак [к], [г] тартыклары әйтелә: *[келәм], [гөл]*. Алар ясалганда, тел арты йомшак аңкауга күтәрелә. Шуңа күрә, [к], [г] – тел арты тартыклары дип атала.

[һ] – йоткылык тартыгы. Бу аваз ясалганда, йоткылык стеналары тарая һәм алар аша һава өрелеп чыгарыла. [х] – кече тел тартыгы. Бу аваз ясалганда, кече тел белән телнең арткы өлеше бер-берсенә якыная һәм һава өрелеп чыгарыла. [һ] һәм [х] – парсыз саңгырау тартыклар.

[н] – тел-теш тартыгы. Аны әйткәндә, тел өске тешләргә тия. [ң] – кече тел тартыгы. Аны әйткәндә, кече тел белән телнең арткы өлеше бер-берсенә якыная. Бу тартыкларны әйткәндә, һава борын аша үтә. Шуңа алар борын тартыклары дип йөртелә.

[ʼ] (һәмзә) – бугаз тартыгы. Бу аваз тавыш ярыларының йомылуы һәм кинәт ачылып китүе нәтиҗәсендә барлыкка килә: *тәэмин – [тәʼмин].*

**Белемнәрне тикшерү өчен сораулар**

1. Татар тел белемендә тартык фонемаларның санына карата булган карашлар (Г.Алпаров, Ф.Г. Исхаков һ.б.).
2. Тартык авазлар сузыклардан нинди билгеләре белән аерылалар?
3. Тартык авазлар нинди принципларга нигезләнеп төркемләнәләр?
4. Ясалу урынына карап тартыклар нинди төркемчәләргә бүленәләр?
5. Ясалу ысулына карап тартыклар нинди төркемчәләргә бүленәләр?
6. Яңгырау һәм саңгырау тартыкларга бүлү нәрсәгә нигезләнә?

## Тема 4. Татар телендә фонетик закончалыклар. Аваз үзгәрешләре. Авазларның комбинатор үзгәрешләре

**Аннотация.** Татар телендә фонетик закончалыклар, комбинатор аваз үзгәрешләр һәм аның төрләре турында мәгълүмат бирелә.

**Терәк сүзләр.** Комбинатор аваз үзгәрешләре, ассимиляция, диссимиляция, аккомодация, яңгырау тартыклар, саңгырау тартыклар.

**Методик тәкъдимнәр.** Тема буенча гомуми күзаллау бирелә. Аны өйрәнергә һәм сорауларга җавап бирергә кирәк.

**Тәкъдим ителә торган информацион чыганаклар:**

**Төп әдәбият**


1. *Сафиуллина, Зәкиев,* 2002. – 216-225 б.

2. *Татар грамматикасы* Т. I, 1998. – 79-88 б.

3. *Хәкимҗан,* 2001. – 56-68 б.

4. *Хисамова,* 1987. – 27-35 б.


**Өстәмә әдәбият**


1. *Алпаров Г.* Сайланма хезмәтләр: (Татар грамматикасы һәм гомуми тел белеме мәсьәләре). – Казан: Татгосиздат, 1945. – 40-45 б.

2. *Богородицкий В.А.* Законы сингармонизма в тюркских языках // Введение в татарское языкознание. – Казань, 1953. – С. 117-132.

3. *Зәкиев М.З., Салихова Д.Ә.* Татар морфонологиясенә кереш. – Казан: КДПИ, 1983. – 32 б.

4. *Исхаков Ф.Г.* Гармония гласных в тюркских языках // Исследования по сравнительной грамматике тюркских языков. - Ч.I. Фонетика. – М.: Изд-во АН СССР, 1955, – С. 122-159.

5. *Кудашев Г.Х.* Татар телендә фонетик һәм морфологик үзгәрешләр // Эзләнүләр, уйланулар, табышлар. – Казан: Таткнигоздат, 1960. – 31-42 б.

6. *Салимов Х.Х.* Аккомодация гласных в татарском языке // Советская тюркология, 1984 - №4. – С. 60 - 68.

7. *Салихова Д.А.* Татар телендә морфонологик күренешләр // Совет мәктәбе, 1983. – №9. – 22-25 б.

8. *Салихова Д.А.* Морфонологическая система современного татарского языка: Автореф дис. … канд. филол. наук. – Казань, 1986. – 20 с.

9. *Сәлимов Х.Х., Закирова Р.М.* Татар теле фонетикасы: Теоретик мәсьәләләр, күнегүләр, табышмаклар һәм башваткычлар – Алабуга, 1998. – 63 б.

10. *Серебренников Б., Гаджиева Н.* Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. – Баку: Маариф, 1979. – С. 7-77.

11. *Сөнгатов Г.М.* Татар теленең фонетик закончалыклары: Теоретик мәгълүмат, күнегүләр һәм биремнәр – Казан: КГУ, 2001. – 4-20 б.

12. *Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков:* Фонетика. – М.: Наука, 1984. – 484 с.

13. *Шакирова Р.Ф.* Хәзерге татар теле фонетикасына кереш – Казан: Таткнигоиздат, 1954. – 76-82 б.

**Тәкъдим ителә торган электрон ресурслар:**

www.wikipedia.ru  Универсальная энциклопедия «Википедия»

www.ksu.ruЭлектронная библиотека и материалы сайта КПФУ

www.slovari.ru  Электронные словари

**Глоссарий**

**Аваз үзгәрешләре** – сөйләм процессында авазларның төрле сәбәпләр нәтиҗәсендә үзгәрүе. Мәсәлән, комбинатор һәм позицион төрләре бар.

**Аккомодация** – төрле характердагы авазларның бер-берсенә җайлашуы, сузыкларның тартыкларга, тартыкларның сузыкларга тәэсире нәтиҗәсендә барлыкка килә торган аваз үзгәрешләре.

**Артикуляция** – сөйләм органнарының нинди дә булса авазны әйткәндәге эшчәнлеге. Ул өч этаптан тора: экскурсия (авазны әйтүгә хәзерлек моменты), тукталыш (авазны әйтү), рекурсия (сөйләм органнарының яңадан үз хәленә кайтуы)

**Ассимиляция** – авазларның әйтелеш һәм яңгыраш ягыннан бер-берсенә охшашлануы.

**Диссимиляция** – авазларның охшашсызлануы. Авыр әйтелешле бертөрле авазларның берсен җиңелрәк әйтелешле икенче бер аваз белән алыштыру. Күбрәк гади сөйләмдә, алынма сүзләрнең әйтелешендә чагылыш таба.

**Комбинатор аваз үзгәрешләре** – төрле комбинацияләрдә килгәндә, авазларның бер-берсенә тәэсир итешү нәтиҗәсендә барлыкка килә торган аваз үзгәрешләре (ассимиляция, аккомодация, диссимиляция).

**Метатеза** – ассимиляция яки диссимиляция нәтиҗәсендә авазларның, иҗекләрнең урыннары алышыну (азбар-абзар).

**Рәт гармониясе** – сингармонизм.

**Редукция** – басымсыз позициядә сузык авазларның үзгәрүе.

**Сандхи –** җөмләдә рәттән әйтелгән сүзләрнең алдагысы сузык авазга тәмамланып, аның артыннан килгәне дә сузык авазга башланса һәм әлеге сүзләр пауза белән бүленмичә, бер синтагма тәшкил итсәләр, чиктәш сузыклар бер-берсенә тоташып, берегеп әйтеләләр.

**Саңгыраулашу** – сүз азагында яки саңгырау тартыклар алдында килгәндә, кайбер яңгырау тартыкларның саңгырау парлары белән чиратлашулары (тозсыз [тоссос]).

**Сингармонизм** – сүз эчендә сузык авазларның рәт һәм иренләшү ягыннан ярашып, охшашланып килүе, сузыклар гармониясе.

**Сингармоник парлар** (сингармоник параллельләр) – этимологик яктан бер үк тамырга караган һәм бары тик рәт гармониясе буенча гына аерыла торган сүзләр.

**Сораулар:**

1. Сөйләмдә аваз үзгәрешләре.
2. Авазларның комбинатор үзгәрешләре.
3. Аккомодациянең күренеше.
4. Ассимиляциянең күренеше.
5. Сингармонизм законы.
6. Сингармоник параллель.

Авазларның әйтелешендә өч момент була:

1. Экскурсия (авазны әйтүгә хәзерлек).

2. Тукталыш (авазны әйтү).

3. Рекурсия (сөйләм органнарының яңадан үз хәленә кайтуы).

Сөйләм процессында бер авазның рекурсиясе икенче, аннан соң килә торган авазның экскурсиясе белән кушылып китә. Авазлар бер-берсенә тәэсир итәләр, төрле аваз үзгәрешләре барлыкка килә.

Сөйләмдә авазлар бер-берсенә ялганып, тоташ агым булып баралар. Шуңа күрә авазларда төрле үзгәрешләр була. Бу үзгәрешләрне, ни сәбәпле булуларыннан чыгып, ике төргә бүләләр: комбинатор һәм позицион үзгәрешләр. Комбинатор үзгәрешләр авазларның бер-берсенә тәэсире нәтиҗәсендә барлыкка килә торган үзгәрешләр. Позицион авазларның сүздәге урынына, позициясенә (сүз башында яки ахырында, басымлы яки басымсыз иҗектә) бәйле үзгәрешләр. Комбинатор үзгәрешләр үзләре өч төрле булалар: аккомодация (җайлашу), ассимиляция (охшашлану), диссимиляция (охшашсызлану).

Аккомодация – төрле табигатьле авазларның бер-берсенә җайлануы, сузыкларның тартыкларга, тартыкларның сузыкларга тәэсире нәтиҗәсендә барлыкка килә торган аваз үзгәрешләре.

I. Сузык авазларның тартыкларга тәэсире:

1. Сузык авазлар тәэсирендә барлык тартыклар калын һәм нечкә вариантта килә алалар: тор – төр, кул – күл, җыр – җир.

2. Иренләшкән сузыклар янында тартыклар беркадәр иренләштереп әйтелә: кил – кул, шәм – шом, сал – сул.

3. [п] [к] [қ] тартыклары ике сузык уртасында яки сузык аваз һәм [р] сонанты арасында килгәндә, үзләренең яңгырау парлары [б] [г] [ғ] белән алыштырыла: сап – сабы, тап – таба, как – кага. Бу күренеш *тартыклар чиратлашуы* дип атала.

II. Тартык авазларның сузыкларга тәэсире:

1. Ирен-ирен тартыклары тәэсирендә [а] авазының иренләшү төсмере көчәя: [ба$^{о}$бай], [ба$^{о}$шак], [ма$^{о}$тур].

2. Тел алды тартыклары тәэсирендә арткы рәт сузыклары беркадәр алдарак әйтеләләр: җыр, чана, чыршы.

3. Кече тел (увуляр) тартыклары тәэсирендә алгы рәт сузыклары калынрак әйтеләләр: кәлтә - [мәқәл], Кәримә - [қәнәғәт].

4. Борын авазлары тәэсирендә сузыклар беркадәр борын төсмере белән әйтеләләр (назальләшәләр): кунак, нарат, таң.

Ассимиляция – авазларның бер-берсенә охшашлануы. Бу күренеш ике төрле була: сингармонизм бер сүз эчендә. Аның ике төре бар: рәт гармониясе бер сүз эчендә сузыкларның калынлыкта-нечкәлектә ярашуы: чирәмлектә, агачлар, ирен гармониясе иренләшкән сузык авазларның үзләреннән соң килгән сузыкларны иренләштерүенә әйтелә:[болот], [төтөн]. Сандхи ике сүз арасында *бара ала [ба$^{о}$рала], кара әтәч [қа$^{о}$рәтәч]*

Сүзләрнең рәт гармониясенә буйсынмау очраклары:

| | |
|---|---|
| 1. Кушма сүзләр | *төньяк, тимераяк* |
| 2. Алынма сүзләр | *китап, ахири, кино* |
| 3. Сыйфатта кимлек дәрәҗәсе -*су* кушымчасы | *зәңгәрсу* |
| 4. Сорау кисәкчәсе -*мыни* | *ардыңмыни?* |
| 5. Кайбер зат алмашлыклары килеш белән төрләнгәндә, калын кушымчалар ялгана | *миңа, сиңа* |

Ассимиляция: диахроник ассимиляция тарихи процесс, аның нәтиҗәсендә, авазлар чиратлашып, яңа кушымчалар барлыкка килгән: *урман – лар › урманнар; күп – дән › күптән.* Язуда чагылыш таба; синхроник ассимиляция җанлы сөйләмдә авазларның охшашлануы: *тот – ып › [тотоп]; тоз – сыз › [тоссос]; унбер › [умбер]*. Сөйләм стилендә орфоэпик норма булмарак.

Сингармоник парлар бер үк тамырга караган, бары рәт гармониясе буенча аерыла торган сүзләр. мәгънә ягыннан аерылган *балакай – бәләкәй, сыпыра – себерә.* мәгънә ягыннан аерылмаган *акрын – әкрен, ата – әти.*

Тартыклар ассимиляциясе:

1. Яңгыраулыкта-саңгыраулыкта ярашу (прогрессив ассим.): төн-нәр, кыш-тан.

2. Борын ассимиляциясе (прогрессив ассим.): болын-нар, урман-нар.

3. Ирен ассимиляциясе (регрессив ассим.): унбер [умбер], син матур [симматур].

4. Тел арты һәм кече тел ассимиляциясе (регрессив ассим.): алдынгы [алдыңгы], иртәнге [иртәңге].

5. [з] [с] авазларына тәмамланган сүзләргә [с] [ч] авазларына башланган кушымчалар ялганса, яки сандхи очрагында бу авазлар [ч] [җ] [ж] [ш] авазлары белән очрашса, регрессив ассимиляция барлыкка килә: кыз + чык [кыччык], сүз + чән [сүччән].

Диссимиляция – сүздә әйтелеше ягыннан охшаш яки якын булган ике авазның берсе алышыну күренеше: [калидур] < коридор, [транвай] < трамвай.

**Белемнәрне тикшерү өчен сораулар**

1. Сөйләмдә аваз үзгәрешләре ничек барлыкка киләләр?

2. Авазларның комбинатор үзгәрешләрен аңлатыгыз.

3. Аккомодациянең асылы нәрсәдә? Төрләрен әйтегез.

4. Ассимиляциянең асылы нәрсәдән гыйбарәт? Төрләрен әйтегез.

5. Сингармонизм законының эчтәлеген аңлатыгыз. Аның нинди төрләре бар?

6. Төрки телләрнең кайсыларында рәт гармониясе сакланмый?

7. Татар телендә сингармонизм законы нинди очракларда бозыла?

8. Сингармоник параллель нәрсә ул? Төрләрен әйтегез.

9. Ирен гармониясе татар язуында чагыламы? Кайсы төрки телләр язуында ирен гармониясе чагыла?

10. Сандхи кайсы очракларда күзәтелә? Мисаллар китерегез.

11. Диссимиляциягә нәрсә сәбәп була? Аның язуда чагылган очраклары бармы?

### Тема 5. Авазларның позицион үзгәрешләре

**Аннотация.** Татар телендә позицион аваз үзгәрешләре һәм аларның төрләре турынди мәгълүмат бирелә.

**Терәк сүзләр.** позицион аваз үзгәрешләре, проклиза күренеше, протеза, энклиза күренеше, эпентеза, эпитеза.

**Методик тәкъдимнәр.** Тема буенча гомуми күзаллау бирелә. Аны өйрәнергә һәм сорауларга җавап бирергә кирәк.

**Тәкъдим ителә торган информацион чыганаклар:**

**Төп әдәбият**

1. *Сафиуллина, Зәкиев,* 2002. – 214-215 б.

2. *Татар грамматикасы* Т. I, 1998. – 79-88 б.

3. *Хәкимҗан,* 2001. – 69-73 б.

4. *Хисамова,* 1987. – 35-38 б.

**Өстәмә әдәбият**

1. *Акбаев Ш.Х.* О причинах редукции в тюркских языках // Советская тюркология. – 1986. – №3. – С. 3-13.

2. *Дмитриев Н.К.* Вставка и выпадение гласных и согласных в тюркских языках // Исследования по сравнительной грамматике тюркских языков. – Ч.I. – Фонетика. – М.: Изд-во АН СССР, 1955. –С. 281-288.

3. *Дмитриев Н.К.* Фонетические закономерности начала и конца тюркского слова // Исследования по сравнительной грамматике тюркских языков. - Ч.I. – Фонетика. – М.: Изд-во АН СССР, 1955. –С. 265-273.

4. *Сәлимов Х.Х., Закирова Р.М.* Татар теле фонетикасы: Теоретик мәсьәләләр, күнегүләр, табышмаклар һәм башваткычлар. – Алабуга, 1998. – 63 б.

5. *Сөнгатов Г.М.* Татар теленең фонетик закончалыклары: Теоретик мәгълүмат, күнегүләр һәм биремнәр. – Казан: КГУ, 2001. – 21-22 б.

6. *Шакирова Р.Ф.* Хәзерге татар теле фонетикасына кереш. – Казан: Таткнигоиздат, 1954. – 83-88 б.

**Тәкъдим ителә торган электрон ресурслар:**

www.wikipedia.ru Универсальная энциклопедия «Википедия»

www.ksu.ruЭлектронная библиотека и материалы сайта КПФУ

www.slovari.ru Электронные словари

**Глоссарий**

**Апокопия** – сүз башындагы яки азагындагы басымсыз сузыкның төшеп калуы: минута > минут, газета > газет.

**Сораулар:**

1. Авазларның позицион үзгәрешләре.
2. Редукция һәм аның төрләре.
3. Татар телендә сүз башы һәм сүз ахыры закончалыгы.
4. Протеза, эпентеза, эпитеза күренешләренең уртаклыгы һәм аермасы.

Позицион аваз үзгәрешләре – авазларның сүздәге урынына, позициясенә (сүз башында, яки ахырында, басымлы яки басымсыз иҗектә) бәйле үзгәрешләр. Төрләре: редукция, протеза, эпентеза, апокопия һ.б.

Проклиза күренеше – кайбер очракларда бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә килгән ике сүзнең (еш кына ул мөстәкыйль сүз һәм ярдәмлек сүз яки кисәкчә була) берсе басымсыз калырга, һәм шуның исәбенә икенче

сүзнең басымы көчәергә мөмкин. Әгәр басымсыз сүз алдан килсә, ул проклитик сүз (проклиза күренеше) була.

Протеза – абсолют сүз башында аваз өстәлү: шляпа-эшләпә.

Энклиза күренеше – кайбер очракларда бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә килгән ике сүзнең (еш кына ул мөстәкыйль сүз һәм ярдәмлек сүз яки кисәкчә була) берсе басымсыз калырга, һәм шуның исәбенә икенче сүзнең басымы көчәергә мөмкин. Әгәр басымсыз сүз ахырдан килсә – энклитик сүз (энклиза күренеше) була.

Эпентеза – фонетик һәм морфонологик шартларга бәйле рәвештә сүздәге ике аваз арасында башлангыч формада булмаган аваз пәйда булу. Татар телендә алынма сүз кабул иткәндә, әгәр алынма сүзнең башында ике янәшә тартык булса, шулар арасына сузык аваз өстәлү: бревно-бүрәнә.

Эпитеза – алынма сүз кабул иткәндә, алынма сүзнең ахырында ике янәшә тартык булса, шуларның ахырына сузык аваз өстәлү: Омск-Омски.

Сүз башында [а] сузыгы иренләшеп әйтелә [а°], сүз ахырына таба аның иренләшүе кими бара. Бу да позицион үзгәрешләрнең бер төре буларак карала.

Сузык авазлар, басымсыз иҗектә килгәндә, беркадәр үзгәрәләр. Бу күренеш редукция дип атала. Ул ике төрле булырга мөмкин: тулы редукция. Сузыклар бөтенләй төшеп калалар: халык – халкым, һәм өлешчә редукция. Сузыкларкыскарак әйтеләләр.

**Белемнәрне тикшерү өчен сораулар**

1. Авазларның позицион үзгәрешләрен аңлатыгыз.

2. Редукция дип нинди күренешкә әйтәбез? Аның нинди төрләре була?

3. Төрки телләрдә кайсы редукция өстенлек ала һәм ни өчен?

4. Татар телендә сүз башы һәм сүз ахыры закончалыгы нинди фонетик үзенчәлекләргә бәйле күзәтелүен аңлатыгыз.

5. Протеза, эпентеза, эпитеза күренешләренең уртаклыгы һәм аермасы нәрсәдә? Мисаллар белән аңлатыгыз.

**Тема 6. Сөйләмнең фонетик кисәкләргә бүленеше. Иҗек. Басым. Интонация.**

**Аннотация**. Сөйләмнең фонетик кисәкләргә бүленеше, иҗек, басым, интонация турында мәгълүмат бирелә.

**Терәк сүзләр.** Иҗек, ачык иҗек, ябык иҗек, иҗек калыплары, басым, сүз басымы, интонация.

**Методик тәкъдимнәр.** Тема буенча гомуми күзаллау бирелә. Аны өйрәнергә һәм сорауларга җавап бирергә кирәк.

**Тәкъдим ителә торган информацион чыганаклар:**

**Төп әдәбият**


1. *Сафиуллина, Зәкиев,* 2002. – 202-213 б.

2. *Татар грамматикасы* Т. I, 1998. – 79-88, 94-103 б.

3. *Хәкимҗан,* 2001. – 69-73 б.

4. *Хисамова,* 1987. – 38-44 б.


**Өстәмә әдәбият**


1. *Абдуллина Р.* Паузалар // Фән һәм мәктәп. – 1997. – №4. – 100-104б.

2. *Абдуллина Р.С.* Риторика һәм интонация. Монография – Яр Чаллы, 1999. – 400 б.

3. *Асылгараев Ш.Н.* Синтагматическое членение татарской речи (Экспериментально-фонетическое исследование): Автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Казань, 1968. – 22 с.

4. *Афлетунов А.Ш.* Словесное ударение в татарском языке // Итоговая конференция КГУ за 1961 г. – Казань, 1962. – С.79-81.

5. *Афлетунов А.Ш.* Логическое ударение в татарском языке // Итоговая конференция КГУ за 1962 г. – Казань, 1963. – С.72-78.

6. *Байчура У.Ш.* Звуковой строй татарского языка – Ч.I. – Казань: Изд-во КУ, 1959. – 140 с.; Ч.II. – Казань: Изд-во КУ, 1961. – 392 с.

7. *Балтаева Р.М.* Интонационная структура общего вопроса в современном татарском языке: Автореф. дис. ... канд. филол. наук – Казань, 1973. – 24 с.

8. *Губайдуллина Г.Т.* Татарская экспериментальная фонетика: истоки и этапы ее развития: Автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Казань, 2011. – 25 с.

9. *Ибрагимов Т.И.* Изучение образования слогов и структуры их сочетаний в татарском литературном языке: Автореф. дис. … канд. филол. наук / – Казань, 1970. – 20 с.

10. Ибраһимов Т. Нәрсә ул иҗек? // Совет мәктәбе. – 1976. – № 11 – 11-12 б.

11. *Исхаков Ф.Г.* Законы словесного ударения в татарском языке // Исследования по сравнительной грамматике тюркских языков. - Ч.I. Фонетика. – М.:Изд-во АН СССР, 1955, – С. 329-332.

12. *Низамов И.М.* Ничек әйтергә? Ничек язарга? Татар интонациясе һәм аны язуда белдерүнең кайбер мәсьәләләре. - Казан, 1990. – 36 б.

13. *Нуриев Г.С.* Сөйләм культурасы: орфоэпия, дикция, интонация. Уку ярдәмлеге – Казан: Печатный двор, 2001. – 152 б.

14. *Нуриев Г.С.* Сәнгатьле сөйләм: Уку ярдәмлеге – Казан: Мәгариф, 2009. – 199 б.

15. *Салимов Х.Х.* Просодическая система татарского языка: Автореф. дис. ... докт. филол. наук. – Казань, 1999. – 64 с.

16. *Хәйруллина А.Х.* Дөрес сөйләргә өйрәнегез – Казан: “Казан” нәшр., 1992. – 96 б.

**Тәкъдим ителә торган электрон ресурслар:**

www.wikipedia.ru  Универсальная энциклопедия «Википедия»

www.ksu.ruЭлектронная библиотека и материалы сайта КПФУ

www.slovari.ru  Электронные словари

**Глоссарий**

**Ачык иҗек** – сузык авазга тәмамланган иҗек.

**Басым** – сөйләмнең берәр берәмлеген (иҗек, сүз) нинди дә булса юл белән башкаларыннан аерып әйтү. Төрләре: сүз басымы, фраза басымы, логик басым, эмфатик басым һ.б.

**Иҗек** – сөйләмнең иң кечкенә берәмлеге. Бер сузык аваздан гына яки сузык янында килгән бер яисә берничә тартыктан тора. *Ачык, ябык* төрләре була.

**Иҗек калыплары** – һәр телнең үзенә генә хас иҗек модельләре бар. Татар телендә 8 иҗек калыбы бар (С – сузык, Т – тартык): С, ТС, СТ, ТСТ, СТТ, ТСТТ – татар теленең үз сүзләрендә; ТТС, ТТСТ – алынма сүзләрдә.

**Логик басым** – җөмләдәге берәр сүзнең мәгънәсен көчәйтү өчен, аны башкаларыннан аерып әйтү. Татар телендә хәбәр алдындагы сүзгә төшә.

**Сөйләм мелодикасы** – сөйләм процессында тавыш югарылыгының үзгәрүе. Интонациянең иң әһәмиятле элементларыннан берсе.

**Ябык иҗек** – тартык авазга тәмамланган иҗек.

**Сораулар:**

1. Сөйләмнең фонетик кисәкләргә бүленеше.

2. Төзелешләреннән чыгып, иҗекләрнең төрләре.

3. Татар телендә иҗек калыбы.

4. Сүз басымы, синтагма басымы, логик басым, сүз басымы, эмфатик басым.

7. Проклиза һәм энклиза күренеше.

8. Татар сөйләменең интонациясе, аның состав өлешләре, функциясе, әһәмияте.

Просодика – фонемаларны бер-берсенә бәйләп, алардан җөмләләр оештыру өчен аларга өстәлә торган фонетик чаралар җыелмасы. Сүзнең просодикасы: иҗек, сүз басымы, ә җөмләнең просодикасы – интонация.

Просодиканың компонентлары: тон югаралагы, озынлык, тавыш көче, пауза, тембр.

Иҗек - әйтелешнең минималь берәмлеге, ул сегмент һәм суперсегмент билгеләренең реальләшү урыны булып хезмәт итә. Хәзерге татар телендә сигез төрле иҗек калыбы бар.

| **Иҗек** | |
|---|---|
| ачык иҗекләр | ябык иҗекләр |
| 1. С: а-та, ә-би, ө-мә, а-ла | 1. С + Т: ир, ат, аш, ал |
| 2. Т + С: ба-ла, ка-ла, са-та | 2. Т + С +Т: таш-лар, бар-ган |
| 3. Т + Т + С: ста-кан | 3. С + Т + Т: ант, урт, әйт-те |
| | 4. Т + С + Т + Т: дүрт, тарт, шалт |
| С - сузык; Т - тартык | 5. Т + Т + С + Т: трак-тор, шкаф, трам-вай |

Сүз басымы ул сүзнең берәр иҗеген төрле юллар белән башкаларыннан аерып әйтү. Татар телендә сүз басымы башка телләр белән чагыштырганда көчсезрәк. Табигате буенча түбәндәгеләрне әйтеп була. Әгәр сүздәге сузыклар озынлык ягыннан бер төрле, я озын, якыска булсалар, һәм басым ахыргы иҗеккә төшсә, басымлы сузык һәрвакыт басымсызыннан озынрак була. Басым беренче иҗеккә төшсә, басымлы сузык басымсызыннан көчлерәк була. Сыйфаты ягыннан басымлы сузык басымсызыннанаерылмый диярлек, татар телендә рус телендәге кебек сыйфат редукциясе булмый.

Татар телендә басым түбәндәге очракларда соңгы иҗеккә төшмәскә мөмкин: 1) II зат боерык фигыльләрдә басым беренче иҗектә була: *языгыз, ташыгыз, утырыгыз;* 2) Исемдә хәбәрлек кушымчалары басымны үзләренә алмыйлар: *язучымын, укытучысың;* 3) Фигыльдә кайбер зат-сан кушымчалары басымны үзләренә алмыйлар: *китәрсең, эшләрмен;* 4) Фигыльдә -*ма*/-*мә* юклык кушымчасы басымны алмый һәм үзеннән үткәрми;

басым фигыльдәге юклык кушымчасы алдындагы иҗеккә төшә: *күрмәде, ташламагыз;* 5) *-мы/-ми* сорау кушымчасы басымны үзенә алмый: *күрдеңме? алдыңмы?;* 6) Хәл фигыль ясагыч *-ганчы/-гәнче, -канчы/-кәнче* кушымчаларына басым төшми: *әйткәнче, барганчы;* 7) Рәвеш ясагыч *-дай/-дәй, -тай/-тәй, -ча/-чә* кушымчалары басымны үзләренә алмыйлар, басым алдагы иҗеккә төшә: *төлкедәй, дусларча;* 8) Хәзерге заман хикәя фигыльгә *-лар/-ләр* күплек сан кушымчасы ялганганда, басым кушымча алдындагы иҗеккә төшә: *карыйлар, баралар, сөйлиләр;* 9) Кайбер гарәп-фарсы алынмаларында басым ахыргы иҗектә булмаска мөмкин: *һәммә, ләкин, әлбәттә;* 10) Соңгырак чорда рус теле аша кергән алынмаларда, шул телдәге басым саклана: *трактор, телевизор.*

Сөйләм агышында аерым сүзләр (еш кына ярдәмлек сүз яки кисәкчә янында), башка сүз басымы астына күчеп, үз басымын югалтырга мөмкин: Фонетик сүз составына кергән басымсыз сүз алдан килсә, ул проклитик сүз (проклиза): 1) *гына/генә, кына/кенә* кисәкчәләре үзләренең алдында килгән исемнәр, саннар, алмашлыкларның басымын үзләренә алалар: *син генә΄, ике генә΄;* 2) Кайбер ияртүче һәм бүлүче теркәгечләрнең (гүя, ягъни, әгәр, я, яисә, яки) басымы аннан соң килгән сүзгә күчә: *я син, я мин..; без, ягъни кешеләр...*

Фонетик сүз составына кергән басымсыз сүз ахырдан килсә, ул энклитик сүз (энклиза): 1) *гына/генә, кына/кенә* кисәкчәләре фигыльләр, рәвешләр, сыйфатлардан соң килгәндә, аларга чикләү төсмере бирә һәм, басымын югалтып, энклитикага әверелә: *тиз генә, ал гына, яшь кенә;* 2) Артыклык дәрәҗәсе ясый торган *ап-, ямь, зәп-, көпә-, туп-, чалт-, шыр, җете, утә, иң* кебек кисәкчәләр сыйфатлар һәм рәвешләр алдында килеп, үзләренә басым кабул итәләр: *иң оста, кып-кызыл, туп-туры, үтә΄ матур;* 3) Мөстәкыйль сүзләрдән соң килгән кайбер теркәгечләр (*ки, да/дә, та/тә, ни – ни*): *килдем дә, алды΄ ни, алмады ни;* 4) Кайбер кисәкчәләр (*бит, ич, ла/лә, ләбаса, да/дә, ук/үк*): *ба΄р ич, күрдем ләбаса, таптым бит;* 5) Кайбер модаль сүзләр (*икән, кирәк, тиеш, соң*): *бара΄ икән, шул кирәк, табарга΄ тиеш;* 6)

Кайбер ярдәмче фигыльләр: *килә´ иде, эшли´ тор, күрмәгән бул;* 7) Парлы сүзләрдә икенче компонент басымсыз була: *бала´-чага, хатын-кыз*.

Интонация – ул сөйләмнең ритмик-мелодик ягы, сөйләмнең мәгънәле кисәкләрен аеру, синтаксик мәгънәләр белдерү, сөйләмгә субъектив мөнәсәбәт белдерү өчен хезмәт итә торган аваз чаралары җыелмасы. Интонация телдә ике функция башкара: коммуникатив, ул сөйләмне җөмләләргә бүлә, җөмлә төрләрен оештыруда катнаша, җөмләне синтагмаларга бүлә; эмоциональ, сөйләүченең халәтен, сөйләмгә мөнәсәбәтен белдерә. Интонациянең компонентлары: тавышның көе, тавышның көче, сөйләмнең тизлеге, паузалар, тавышның тембры.

**Белемнәрне тикшерү өчен сораулар**

1. Сөйләм нинди фонетик кисәкләргә бүленә?

2. Нәрсә ул иҗек?

3. Төзелешләреннән чыгып, иҗекләрне нинди төрләргә бүләләр?

4. Татар телендә ничә иҗек калыбы бар?

5. Сүз басымына билгеләмә бирегез.

6. Сүз басымының урынына карап, телләрне ирекле басымлы һәм даими басымлы телләргә бүлеп йөртәләр. Төрки телләр кайсы телләргә карый?

7. Татар телендә басымның соңгы иҗеккә төшмәү очракларын әйтегез.

8. Синтагма басымы, логик басым, сүз басымы бер-берсеннән нәрсә белән аерылалар?

9. Эмфатик басым нәрсә ул?

10. Проклиза һәм энклиза нинди шартларда күзәтелә?

11. Татар сөйләменең интонациясе, аның состав өлешләре, функциясе, әһәмияте турында сөйләгез.

## Тема 7. Графика һәм орфография

**Аннотация.** Графика һәм алфавит, язу тарихы, орфография һәм языдыш принциплары турында мәгълүмат бирелә.

**Терәк сүзләр.** Графика, алфавит, хәреф, орфография, фонетик принцип, морфолологик принцип, тарихи-традицион принцип, график принцип.

**Методик тәкъдимнәр.** Тема буенча гомуми күзаллау бирелә. Аны өйрәнергә һәм сорауларга җавап бирергә кирәк.

**Тәкъдим ителә торган информацион чыганаклар:**

**Төп әдәбият**


1. *Курбатов Х.Р.* Татар әдәби теленең алфавит һәм орфография тарихы. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1960.– 132б.; Казан: Тат.кит.нәшр.,1999. – 139 б.

2. *Сафиуллина, Зәкиев,* 2002. – 235-241 б.

3. *Татар грамматикасы* Т. I, 1998. – 104-133 б.

4. *Хәкимҗан,* 2001. – 91-101 б.

5. *Хисамова Ф.М.* Татар теле: Латин әлифбасына кайтуның фәнни нигезләре. – Казан: Школа, 2004. – 72 б.

6. Мифтахов Б.М. Татар теле орфографиясе һәм пунктуациясенең кыен очраклары. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1970. –160 б.


**Өстәмә әдәбият**


1. *Абдуллина Р.С.* Алфавитка бәйле орфография һәм орфоэпия мәсьәләләре. – Казан: Тат.кит.нәшр., 2006. – 284 б.

2. *Абдуллина Р.С.* Хәзерге татар теленең орфографиясе һәм орфоэпиясе: Югары һәм урта махсус уку йортлары студентлары өчен уку әсбабы. – Казан: Мәгариф, 2009. – 239 б.

3. *Амирова Т.А.* Функциональная взаимосвязь письменного и звукового языка. – М.: Наука, 1985.

4. *Газизова Ф.М.* Татар теленең латинда һәм кирилда орфография сүзлеге. – Казан, 2004.

5. *Ганиев Ф.* Татар теле орфографиясенең фәнни нигезләре // Мәгариф. 2001. - №7. – 11-12 б.

6. *Закиев М.З.* Тюрко-татарское письмо. История, состояние, перспективы. – М.: Инсан, 2005. – 247 с.

7. *Зәйнуллин Җ.Г.* Гарәп язуы нигезендә татарча әлифба. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – 126 б.

8. *Икетеллелек шартларында татар орфографиясе һәм орфоэпиясенең актуаль проблемалары:* Татар филологиясе һәм тарихы факультеты студентлары өчен махсус курс программасы / Төз: Г.Р. Галиуллина. – КГУ, 2004. – 6 б.

9. *Иоганнес Фридрих.* История письма. – М., 1979.

10. *Махмутов М.И.* Фонетическое и грамматическое освоение арабских заимствований в татарском литературном языке: Дис. … канд. филол. наук. – Казань, 1966. – 361 с.

11. *Нуриева А.Х.* Татар теленең орфографик сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 1996. – 144 б.

12. *Опыт совершенствования алфавитов и орфографий языков народов СССР.* – М.: Наука, 1982.

13. *Саттаров Г.Ф.* Татар исемнәре ни сөйли? – Казан: “Раннур”, 1998. – 485 б.

14. *Сәлимов Х.Х.* Татар теленең орфографик-орфоэпик сүзлеге. – Казан: Яңалиф, 2004. – 191 б.

15. *Сәлимов Х.Х.* Авыр орфограммалар сүзлекчәсе. – Алабуга: Алабуга пед.ун-ты нәшр., 2004.

16. *Сәлимов Х.Х.* Тел гыйлеме терминнары сүзлеге. – Казан: Тат. кит. нәшр., 2005. – 142 б.

17. *Сөнгатов Г.М.* Орфография кагыйдәләре әйтелешкә нигезләнсен // Мәгариф, 1999. – №10. – 38-42 б.

18. *Сөнгатов Г.М.* Алфавит алыштыру һәм орфография кагыйдәләре // Мәгариф, 2000. – №12. – 14-16 б.

19. *Татар теленең орфографик сүзлеге* / Төз.: А.Х. Нуриева, Ф.С. Фасеев, М.И. Мәхмүтов. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1983. – 280 б.

20. *Татар теленең орфография сүзлеге*: 140000 чамасы сүз һәм сүз формасы теркәлде / Төз.: Ф.Ә. Ганиев, И.И. Сабитова – Казан, 2002. – 432 б.

21. *Татар теленең орфографик сүзлеге.* / Төз.: К.Р. Галиуллин, Р.И. Раскулова Казан: Мәгариф, 2010. – 399 б.

22. *Татарско-русский словарь личных имен и фамилий* / Авт.-сос.: Г.Ф. Саттаров, Р.Г. Ахметьянов, Ф.Г. Ганиев, И.А. Абдуллин, Г.С Сабирзянов, К.Р. Галиуллин, Г.Р. Галиуллина. Казань: Татар. Кн. изд-во. – 375 с.

23. *Хакимзянов Ф.С.* Язык эпитафий волжских булгар. – М.: Наука, 1978. – 208 с.

24. *Шакирҗанова Ә.Б.* Татар теле орфографиясенең кыен очраклары һәм укучыларның грамоталылыгын күтәрү юллары. – Казан: Казан унив.нәшр., 2004. – 134 б.

**Тәкъдим ителә торган электрон ресурслар:**

www.wikipedia.ru Универсальная энциклопедия «Википедия»

www.ksu.ruЭлектронная библиотека и материалы сайта КПФУ

www.slovari.ru Электронные словари

**Глоссарий**

**График принцип** – рус теленнән һәм рус теле аша кергән алынма сүзләрне тамыр һәм нигез өлешләрен шул телдәгечә язу. Рус теленнән элегрәк кергән сүзләр фонетик принцип нигезендә язылa (сумала, эскәтер).

**Графика** – нинди дә булса телнең язу чаралары җыелмасы. Тел гыйлеменең авазлар белән хәрефләр арасындагы мөнәсәбәтләрне өйрәнә торган бүлеге.

**Морфологик принцип** – морфемаларны, ничек ишетелүенә карамастан, һәрвакыт бер генә төрле язу. Мәсәлән, о, ө хәрефләренең беренче иҗектә генә язылуы, кайбер аваз үзгәрешләренең язуда күрсәтелмәве: унбиш [умбиш].

**Орфограмма** – орфография кагыйдәләренә туры килә һәм шул кагыйдәләрне куллануны таләп итә торган язылыш.

**Орфография** – дөрес язу кагыйдәләре җыелмасы. Сүзләрнең һәм кушымчаларның, кушма һәм кыскартылма сүзләрнең дөрес язылышын, баш хәрефтән язу, сүзләрне юлдан юлга күчерү кагыйдәләрен үз эченә ала. Төп принциплары: фонетик, морфологик, график, тарихи-традицион.

**Тарихи-традицион принцип** – шул телнең элеккеге язу үзенчәлекләрен, традицияләрен саклап язу: бәла, һәлак һ.б.

**Фонетик принцип** – ишетелгәнчә язу. Хәзерге татар язуы башлыча шушы принципка корылган.

**Хәреф** – бер телнең алфавит составындагы график тамга. Авазларны язуда белдерү өчен хезмәт итә.

**Язу** – график тамгалар системасы ярдәмендә аралашу чарасы.

**Сораулар:**

1. Графика, татар язуының кыскача тарихы.
2. Татар алфавиты.
3. Татар телендә орфографиянең язылыш принциплары.

Татарларның язу тарихы бик катлаулы. Безнең ерак бабаларыбыз рун язуыннан файдаланганнар. 922 нче елда болгарлар ислам дине кабул иткәч, рун язуы гарәп язуы белән алышына.

XX гасыр башларында төрки халыкларга латин язуын кертү хәрәкәте башлана. Татарлардан беренче булып бу фикерне С. Рәмиев күтәреп чыга. 1927 нче елда хөкүмәтнең махсус карары белән латин алфавиты татарларның

рәсми язуы буларак кабул ителә. 1937 нче елда татарлар кириллица язуына күчәләр һәм хәзерге көнгә кадәр шушы язуны кулланалар.

Хәрефләрнең формасы һәм аларның телдәге авазларга ни дәрәҗәдә туры килүен тел гыйлеменең графика (грекча graphike “рәсем төшерү”) дигән бүлеге өйрәнә. Алфавиттагы хәрефләрне кулланып, сүзләрне дөрес язу орфография кагыйдәләре тарафыннан билгеләнә.

Язуда кулланыла торган хәрефләрнең кабул ителгән тәртиптәге җыелмасы алфавит дип атала. Татар алфавитында 39 хәреф бар, (шуларның 9ы – сузык аваз хәрефләре, 3 хәреф – я, ю, е – икешәр аваз кушылмасын белдерә, 24е тартык авазларны белдерә һәм аваз белдерми торган ике махсус билге (ъ, ь) бар).

Аа Әә Бб Вв Гг Дд Ее Ёё Жж Җҗ Зз Ии Йй Кк Лл Мм Нн ң Оо Өө Пп Рр Сс Тт Уу Үү Фф Хх Һһ Цц Чч Шш Щщ ъ Ыы ь Ээ Юю Яя

Орфография (грекча orthos “дөрес” һәм grapho “язам”) – гомум кабул ителгән, бердәм нормаларга салынган һәм һәркемгә мәҗбүри саналган практик язу системасы, ягъни әдәби телнең фәнни нигезләнгән, дәүләт тарафыннан законлаштырылган язу кагыйдәләре җыелмасы.

Татар орфографиясенең төп принциплары:

Фонетик принцип – сүздәге авазларны ишетелгәнчә язу: урамнар, халык, дәфтәр.

Морфологик принцип – сүздәге морфемаларны һәрвакыт бер төрле язудан һәм сүз үзгәргәндә туган аваз үзгәрүен күрсәтеп тормаудан гыйбарәт: унбиш, әнкәй, иртәнге, болын, сөлге.

Тарихи-традицион принцип – шул телнең элекке язу үзенчәлекләрен, традицияләрен саклап язу: сурәт, 6 шар алма.

График принцип – рус теленнән һәм рус теле аша кергән сүзләрне рус телендәгечә язу: комитет, автомат, компьютер.

Дифференциацияләнгән язылыш – омонимик сүзләрне бер-берсеннән аеру өчен кулланыла: байрак – баерак, биш бармак – бишбармак.

Авазларның язылыш кагыйдәләре:

В хәрефе ирен-ирен [w] тартыгын һәм ирен-теш [в] тартыгын белдерә: *җавап, витрина.*

Алынма сүзләрдә һәм фамилияләрдә в хәрефе [ф] булып ишетелә, ләкин в хәрефе языла: *Галиев [гәлийеф].*

Сүз һәм иҗек ахырындагы у, ү хәрефләре ирен-ирен [w] тартыгын белдерә: *тау, дәү, тәүге, чәүкә.*

Нечкә сүзләрдә [к], [г], ә калын сүзләрдә [къ], [гъ] тартыклары әйтелә. Бу авазлар язуда к, г хәрефләре белән языла: *кала, килә, гөл, Гамир.*

Гарәп-фарсы сүзләрендә [къ], [гъ] тартыклары нечкә сүзләрдә дә килә ала: *мәгънә, тәкъдим.*

Нечкә сүзләрдә ачык иҗек башында килгән [къ], [гъ] авазларының катылыгын язуда калын сузык аваз хәрефләре белдерә: *каләм* - *[къә-ләм].*

Нечкә сүзләрдә ябык иҗек ахырында килгән [къ], [гъ] авазларының катылыгын язуда ъ хәрефе белдерә: *микъ-дар [микъ-дар].*

**Белемнәрне тикшерү өчен сораулар**

1. Графика нәрсәне өйрәнә?

2. Татар язуының кыскача тарихын сөйләп бирегез.

3. Татар алфавитын яттан әйтегез. Авазны белдерми торган һәм ике аваз билгесе булып йөри торган хәрефләрне әйтегез. Тартык фонема сузык аваз хәрефе белән күрсәтелергә мөмкинме?

4. Хәзерге татар алфавитында үзенең махсус хәрефләре булмаган авазларны әйтегез.

5. Орфография нинди фән ул?

6. Татар телендә орфографиянең нинди язылыш принциплары кулланыла?

7. Хәзерге вакытлы матбугатта орфография кагыйдәләре сакланамы? Мисаллар туплагыз.

## Тема 8. Орфоэпия

**Аннотация.** Орфоэпия турында гомуми мүгълүмат бирелә. Әдәби әйтелеш нормалары: тулы стиль һәм сөйләшү стиле, татар теленең орфоэпиясен фәнни нигездә камилләштерергә кирәклеге турында нәтиҗә чыгарыла.

**Терәк сүзләр.** Орфоэпия, дөрес әйтелеш нормалары.

**Методик тәкъдимнәр.** Тема буенча гомуми күзаллау бирелә. Аны өйрәнергә һәм сорауларга җавап бирергә кирәк.

**Тәкъдим ителә торган информацион чыганаклар:**

**Төп әдәбият**


1. *Сафиуллина, Зәкиев,* 2002. – 225-234 б.

2. *Татар грамматикасы* Т. I, 1998. – 134-151 б.

3. *Хәкимҗан,* 2001. – 102-105 б.


**Өстәмә әдәбият**


1. *Абдуллина Р.С.* Алфавитка бәйле орфография һәм орфоэпия мәсьәләләре. – Казан: Тат.кит.нәшр., 2006. – 284 б.

2. *Абдуллина Р.С.* Стилистика һәм сөйләм культурасы мәсьәләләре. Монография – Яр Чаллы:“КамАЗ” нәшрияты, 1997. – 156 б.

3. *Җәләй Л.* Татар теленең орфоэпик нигезләре. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1953. – 72 б.

4. *Курбатов Х.Р.* Орфоэпия // Хәзерге татар әдәби теле: Лексика, фонетика, орфоэпия, графика һәм орфография, морфология: Югары уку йорты студ. һәм урта мәктәп укытучылары өчен. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1965. – 133-153 б.

5. *Низамов И.М.* Уем – тел очында: Сөйләм һәм массакүләм аралашу. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1995. – 287 б.

6. *Ногман М.* Татар тел культурасы тарихыннан // Совет мәктәбе – 1957. – №7. – 100-109 б.

7. *Нуриев Р.* Татар сәхнә сөйләме. – Казан: Мирас. – 1998.

8. *Нуриев Р.* Сәнгатьле уку: Методик ярдәмлек. – Казан: Мастер Лайн, 2000. – 152 б.

9. *Сагдеева Ф.К.* Проблемы культуры татарской речи в условиях активного двуязычия. – Казан:“ Фикер”, 2003. – 159 с.

10. *Саттаров Г.Ф.* V-VIII класс укучыларының тел культурасын үстерү. - Казан: КДУ нәшр, 1962.

11 *Саттаров Г.Ф.* Мәктәптә тел культурасы. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1965. – 151 б.

12. *Сәлимов Х.Х., Гыйзәтдинова Г.Х.* Татар теленең орфоэпик сүзлеге. – Чаллы: Камаз, 1995. –127 б.

13. *Хангилдин В.Н.* Татар теленең орфоэпик нормалары мәсьәләсе / Совет мәктәбе – 1941. - №5. – 15-17 б.

14. *Хәйруллина А.Х.* Дөрес сөйләргә өйрәнегез. – Казан: “Казан” нәшр., 1992. – 96 б.

15. *Юсупов Р.А.* Укучыларда сөйләм культурасы тәрбияләү / Р.А. Юсупов. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1983. – 137 б.

16. *Юсупов Р.А.* Инсафлының теле саф (Дөрес сөйләм турында иншалар). – Казан: КГПИ, 1993. – 162 б.

17. *Юсупов Р.А.* Әдәп башы – тел: Икетеллелек шартларында дөрес сөйләм мәсьәләләре. – Казан: КДПУ, 2000. – 218 б.

18. *Юсупов Р.А.* Икетеллелек һәм сөйләм культурасы. – Казан: Тат.кит.нәшр., 2003. – 223 б.

19. *Юсупов Ф.Ю.* Җирле сөйләш шартларында фонетика укыту. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1977. – 165 б.

**Тәкъдим ителә торган электрон ресурслар:**

www.wikipedia.ru Универсальная энциклопедия «Википедия»

www.ksu.ruЭлектронная библиотека и материалы сайта КПФУ

www.slovari.ru Электронные словари

**Глоссарий**

**Орфоэпия** – дөрес әйтелеш кагыйдәләренең, нормаларының җыелмасы.

**Сораулар:**

1. Орфоэпия һәм дөрес сөйләм.
2. Дөрес әйтелеш нормалары.

Әдәби телдәгечә дөрес әйтелеш кагыйдәләре орфоэпия (orthos "дөрес" һәм epos "сөйләү") дип йөртелә.

Язуда авазлар хәрефләр белән белдерелә. Авазларны әйтәбез һәм ишетәбез. Хәрефләрне язабыз һәм укыйбыз.

Сүзләрнең дөрес әйтелеше орфоэпик сүзлекләрдә бирелә.

Дөрес әйтелеш кагыйдәләре үтәлмәсә, әңгәмәдәшләр бер-берсен аңламый, сөйләм күңелсез, мәгънәсез була. Белемле, укымышлы, тәрбияле кеше дөрес сөйләм кагыйдәләрен яхшы белә. Дөрес сөйләм кешеләргә бер-берсен тизрәк аңларга ярдәм итә.

Дөрес сөйләм телен үстерүгә мәктәп, телевидение, радио, кино, театр зур йогынты ясый. Сөйләм культурасына ия булу өчен орфоэпик сүзлеккә карарга, укытучылар, актёрлар, сәнгатьле сөйләм осталарының сөйләмен тыңларга кирәк.

Авазларның әйтелешен язуда күрсәтү транскрипция (латин теленнән transcription «күчереп язу») дип атала. Авазларны, язудагы хәрефләр белән бутамас өчен, квадрат җәяләр эчендә бирәләр: *авыл – [а] [w] [ы] [л].*

Әдәби әйтелеш ике төрле: тулы стиль, сөйләмнең бик анык булуы таләп ителгән очракларда (диктор сөйләмендә, лекция укыганда, дәрес биргәндә), ягъни сөйләүче язма тел стильләренең берсе белән эш иткәндә

кулланыла; сөйләшү стиле, кешеләрнең үзара сөйләшеп аралашуларында – диалогларда кулланыла

Татар теленең әдәби әйтелеше Казан сөйләшенә нигезләнгән. Казан шәһәре күп гасырлар буе татар халкының мәдәни, сәяси үзәге булып килгәнлектән, Казан татарларының сөйләше башкалар өчен дә үрнәк була башлаган. Язма әдәбиятның бу тирәгә күбрәк туплануы нык тәэсир иткән.

Татар теленең орфоэпик нормалары түбәндәге принципларга корылган:

1. Орфоэпия гомумхалык телендәге әйтелеш нормаларына нигезләнә.

2. Теге яки бу нормаларның, сүзләрнең әдәбиятта беркетелгән булулары һәм эстетик көчле булуы кирәк.

3. Әдәби тел орфографиясендә морфологик нигездә язылыш нормалары орфоэпиядә дә саклана.

4. Рус теленнән һәм аның аша башка телләрдән кергән сүзләрнең

Әйтелешләре рус орфоэпик нормаларына охшаш була. Моңа борынгы үзгәргәналынмалар керми.

Әдәби әйтелешне бозып сөйләү берничә төрле сәбәптән булырга мөмкин.

Язылыш белән әйтелеш арасында зур аерма яшәп килә: сүз бертөрле языла, икенче төрле әйтелә. Мондый хәл орфографик кагыйдәләрнең, графиканың төгәл булмавыннан килә: гомер [гъөмөр], канәгать [къәнәгъәт], кыйммәт [къиммәт] һ.б.

Әдәби телгә диалект һәм сөйләшләрнең йогынтысы була, һәм алар тәэсирендә әдәби әйтелеш нормалары үзгәрергә мөмкин: мәсәлән, җырак (ерак), бәк матур (бик матур), әчкеч (ачкыч), назан (надан), телке (төлке) һ.б. Бу турыда методика фәнендә Г.Ф. Саттаров һәм Ф.Й. Юсупов шактый мәгълүмат туплап язып чыкканнар. (Саттаров Г.Ф. Мәктәптә тел культурасы. – Казан, 1965.; Йосыпов Ф.Ю. Җирле сөйләм шартларында фонетика укыту. – Казан, 1977.)

Әдәби әйтелешкә рус теленең кире йогынтысы да булырга мөмкин. рус телендәге [о] авазыннан аермалы буларак, татар телендәге [о] авазы кыска сузык аваз: тоз, он, борын һ.б. Чыгышы ягыннан ул борынгы төрки телендәге [u] авазына барып тоташа: тоз < tuz, он < un, борын < burun. Укучылар [ŏ] авазын нәкъ рус телендәге кебек, озынрак, киңрәк итеп әйтәләр: [он], [тоз], [борон].

**Белемнәрне тикшерү өчен сораулар**

1. Орфоэпия нәрсәне өйрәнә? Дөрес сөйләргә нинди факторлар комачаулык итә?

2. Хәзерге татар язуында орфоэпиягә һәм орфографиягә йогынты ясый торган күп функцияле хәрефләрне әйтегез. Мисаллар китерегез.

3. Татар телендә "һәмзә" авазының орфоэпиясе һәм орфографиясе турында сөйләгез.

4. Сузыклар орфоэпиясендә аеруча игътибар ителергә тиешле күренешләрне әйтегез.

5. Тартыклар әйтелешендә төп игътибар ителергә тиешле күренешләрне санагыз.

6. Дөрес әйтелеш нормаларын өйрәнүгә һәм эшкәртүгә зур өлеш керткән татар галимнәренең хезмәтләрен әйтегез.

**Глоссарий**

**Аваз** – сөйләмнең таркалмый торган иң кечкенә берәмлеге.

**Аваз үзгәрешләре** – сөйләм процессында авазларның төрле сәбәпләр нәтиҗәсендә үзгәрүе. Мәсәлән, комбинатор һәм позицион төрләре бар.

**Аккомодация** – төрле характердагы авазларның бер-берсенә җайлашуы, сузыкларның тартыкларга, тартыкларның сузыкларга тәэсире нәтиҗәсендә барлыкка килә торган аваз үзгәрешләре.

**Актив органнар** – артикуляция процессында хәрәкәтләнә торган органнар. Мәсәлән, тел, йомшак аңкау, иреннәр, тавыш ярылары, үпкәләр.

**Акустик аспект (физик аспект)** – авазларны өйрәнүнең бер аспекты, авазларны физик күренеш буларак, тавыш дулкыннарының тирбәнеше дип карау.

**Алгы рәт сузыклар** – авыз куышлыгының алгы өлешендә ясала торган сузыклар, ягъни нечкә сузыклар.

**Альвеола** – теш казнасы.

**Апокопия** – сүз башындагы яки азагындагы басымсыз сузыкның төшеп калуы: минута > минут, газета > газет.

**Артикуляция** – сөйләм органнарының нинди дә булса авазны әйткәндәге эшчәнлеге. Ул өч этаптан тора: экскурсия (авазны әйтүгә хәзерлек моменты), тукталыш (авазны әйтү), рекурсия (сөйләм органнарының яңадан үз хәленә кайтуы)

**Арткы рәт сузыклар** – авыз куышлыгының арткы өлешендә ясала торган сузыклар, ягъни калын сузыклар.

**Ассимиляция** – авазларның әйтелеш һәм яңгыраш ягыннан бер-берсенә охшашлануы.

**Ачык иҗек** – сузык авазга тәмамланган иҗек.

**Басым** – сөйләмнең берәр берәмлеген (иҗек, сүз) нинди дә булса юл белән башкаларыннан аерып әйтү. Төрләре: сүз басымы, фраза басымы, логик басым, эмфатик басым һ.б.

**Вокализм** – телнең сузык авазлар системасы. Сузык авазларның билгеләре һәм алар арасындагы мөнәсәбәтләр.

**Гомуми фонетика** – төрле телләр өчен уртак булган аваз һәм фонема, аваз үзгәрешләре, авазларны төркемләү, иҗек, басым, сөйләмнең фонетик кисәкләргә бүленешенең теоретик мәсьәләләрен хәл итә.

**График принцип** – рус теленнән һәм рус теле аша кергән алынма сүзләрне тамыр һәм нигез өлешләрен шул телдәгечә язу. Рус теленнән элегрәк кергән сүзләр фонетик принцип нигезендә языла (сумала, эскәтер).

**Графика** – нинди дә булса телнең язу чаралары җыелмасы. Тел гыйлеменең авазлар белән хәрефләр арасындагы мөнәсәбәтләрне өйрәнә торган бүлеге.

**Диссимиляция** – авазларның охшашсызлануы. Авыр әйтелешле бертөрле авазларның берсен җиңелрәк әйтелешле икенче бер аваз белән алыштыру. Күбрәк гади сөйләмдә, алынма сүзләрнең әйтелешендә чагылыш таба.

**Дифтонг** – ике сузык авазның бер иҗектә килүе. *Чын дифтонглар* инглиз, алман телләренә, ә *ялган дифтонглар* татар һәм рус телләренә хас. Сузык аваз белән [й] яки [w] тартыкларының кушылмаларын ялган дифтонг дип атыйлар. Ике төре бар: *күтәрелмә* (башта ярымсузык [й] яки [w] тартык авазы килә: йа, йу, wa һ.б.); *төшерелмә* (башта сузык аваз килә: ай, әй, әw һ.б.)

**Дифференциаль билге** – берәр фонеманы башкаларына каршы куя, башкаларыннан аера торган билге. Мәсәлән, яңгыраулык-саңгыраулык, озынлык-кыскалык һ.б.

**Иҗек** – сөйләмнең иң кечкенә берәмлеге. Бер сузык аваздан гына яки сузык янында килгән бер яисә берничә тартыктан тора. *Ачык, ябык* төрләре була.

**Иҗек калыплары** – һәр телнең үзенә генә хас иҗек модельләре бар. Татар телендә 8 иҗек калыбы бар (С – сузык, Т – тартык): С, ТС, СТ, ТСТ, СТТ, ТСТТ – татар теленең үз сүзләрендә; ТТС, ТТСТ – алынма сүзләрдә.

**Каты аңкау** – авыз куышлыгының өске алгы өлеше. Кайбер авазларны әйткәндә катнаша торган пассив сөйләм органы.

**Кнаклаут** – бугаз тартыгы (һәмзә).

**Комбинатор аваз үзгәрешләре** – төрле комбинацияләрдә килгәндә, авазларның бер-берсенә тәэсир итешү нәтиҗәсендә барлыкка килә торган аваз үзгәрешләре (ассимиляция, аккомодация, диссимиляция).

**Консонантизм** – телнең тартыклар системасы, тартыкларның үзенчәлекләре һәм үзара мөнәсәбәтләре.

**Коррелят** – бер билгесе белән генә аерылып торган фонема оппозицияләре: [а] - [ә], [б] - [п] һ.б.

**Лабиальләшү** – иренләшү. Авазларны әйткәндә, төп артикуляциягә өстәмә рәвештә иреннәрнең түгәрәкләнеп алга таба сузылулары.

**Лабио-денталь** – ирен-теш тартыклары.

**Ларингаль** – бугаз тартыгы (һәмзә тартыгы).

**Логик басым** – җөмләдәге берәр сүзнең мәгънәсен көчәйтү өчен, аны башкаларыннан аерып әйтү. Татар телендә хәбәр алдындагы сүзгә төшә.

**Метатеза** – ассимиляция яки диссимиляция нәтиҗәсендә авазларның, иҗекләрнең урыннары алышыну (азбар-абзар).

**Морфологик принцип** – морфемаларны, ничек ишетелүенә карамастан, һәрвакыт бер генә төрле язу. Мәсәлән, о, ө хәрефләренең беренче иҗектә генә язылуы, кайбер аваз үзгәрешләренең язуда күрсәтелмәве: унбиш [умбиш].

**Морфонология** – тел гыйлеменең бер тармагы, морфология һәм фонология фәннәре арасында тора. Төрле морфологик процесслар вакытында морфемаларда бара торган фонетик үзгәрешләрне, чиратлашуларны өйрәнә.

**Нечкә сузыклар** – алгы рәт сузыклары, авыз куышлыгының алгы өлешендә ясала торган сузыклар.

**Озын сузыклар** – артикуляцияләре бердәй һәм бер-берсеннән бары яңгырау озынлыгы белән генә аерыла торган сузыклар.

**Орфограмма** – орфография кагыйдәләренә туры килә һәм шул кагыйдәләрне куллануны таләп итә торган язылыш.

**Орфография** – дөрес язу кагыйдәләре җыелмасы. Сүзләрнең һәм кушымчаларның, кушма һәм кыскартылма сүзләрнең дөрес язылышын, баш хәрефтән язу, сүзләрне юлдан юлга күчерү кагыйдәләрен үз эченә ала. Төп принциплары: фонетик, морфологик, график, тарихи-традицион.

**Орфоэпия** – дөрес әйтелеш кагыйдәләренең, нормаларының җыелмасы.

**Позицион аваз үзгәрешләре** – авазларның сүздәге урынына, позициясенә (сүз башында, яки ахырында, басымлы яки басымсыз иҗектә) бәйле үзгәрешләр. Төрләре: редукция, протеза, эпентеза, апокопия һ.б.

**Проклиза күренеше** – кайбер очракларда бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә килгән ике сүзнең (еш кына ул мөстәкыйль сүз һәм ярдәмлек сүз яки кисәкчә була) берсе басымсыз калырга, һәм шуның исәбенә икенче сүзнең басымы көчәергә мөмкин. Әгәр басымсыз сүз алдан килсә, ул проклитик сүз (проклиза күренеше) була.

**Протеза** – абсолют сүз башында аваз өстәлү: шляпа-эшләпә.

**Рәт** – сузык авазларны әйткәндә, телнең горизанталь юнәлештәге торышы. Сузыклар алгы рәт, арткы рәт сузыкларына бүленәләр.

**Рәт гармониясе** – сингармонизм.

**Редукция** – басымсыз позициядә сузык авазларның үзгәрүе.

**Сандхи –** җөмләдә рәттән әйтелгән сүзләрнең алдагысы сузык авазга тәмамланып, аның артыннан килгәне дә сузык авазга башланса һәм әлеге сүзләр пауза белән бүленмичә, бер синтагма тәшкил итсәләр, чиктәш сузыклар бер-берсенә тоташып, берегеп әйтеләләр.

**Саңгырау тартыклар** – артикуляция вакытында тавыш ярылары хәрәкәтләнми, шунлыктан тавыштан башка, шау ярдәмендә генә әйтелә торган тартык авазлар.

**Саңгыраулашу** – сүз азагында яки саңгырау тартыклар алдында килгәндә, кайбер яңгырау тартыкларның саңгырау парлары белән чиратлашулары (тозсыз [тоссос]).

**Сегмент берәмлекләр –** билгеле бер эзлеклелектә килә торган авазлар. Шул авазлар тезмәсе икенче бер сегмент берәмлекне – иҗекне формалаштыра

**Сингармонизм** – сүз эчендә сузык авазларның рәт һәм иренләшү ягыннан ярашып, охшашланып килүе, сузыклар гармониясе.

**Сингармоник парлар** (сингармоник параллельләр) – этимологик яктан бер үк тамырга караган һәм бары тик рәт гармониясе буенча гына аерыла торган сүзләр.

**Синтаксик фонетика** – сөйләмнең фонетик кисәкләрен, басым һәм интонацияне тикшерә.

**Сөйләм аппараты** – кешенең сөйләм барлыкка китерә торган әгъзалары җыелмасы.

**Сөйләм мелодикасы** – сөйләм процессында тавыш югарылыгының үзгәрүе. Интонациянең иң әһәмиятле элементларыннан берсе.

**Сузык авазлар** – акустик яктан тавыштан гына торалар, әйткәндә һава агымының сөйләм аппараты аша тоткарлыксыз үтеп китүе нәтиҗәсендә ясалалар, иҗек төзиләр.

**Суперсегмент берәмлекләр** – аваз һәм иҗекләрдән зуррак булган сүз һәм фразаны характерлаучы берәмлекләр.

**Тарихи-традицион принцип** – шул телнең элеккеге язу үзенчәлекләрен, традицияләрен саклап язу: бәла, һәлак һ.б.

**Тарихи фонетика** – конкрет бер телдәге аваз системасының төрле чорлар дәвамындагы үсеш-үзгәрешен тикшерә.

**Тасвирлама фонетика** – аерым бер телнең билгеле бер үсеш этабындагы авазлар системасын тасвирлау, аларның яшәешен өйрәнү белән шөгыльләнә.

**Транскрипция** – тел белемендә кулланыла торган махсус язу системасы. Әйтелешне тулысынча язуда күрсәтү өчен хезмәт итә.

**Транслитерация** – чит тел сүзләрен үз телендәге хәрефләр белән язу.

**Увуляр тартык** – кече тел тартыгы.

**Фарингаль тартык** – йоткылык тартыгы.

**Фонема** – телдәге сүзләрне һәм морфемаларны төзи, аларны бер-берсеннән аерырга ярдәм иткән аваз системасының иң кечкенә берәмлеге. Татар телендә - 12 сузык, 28 тартык фонема бар.

**Фонетика** – тел белеменең бер бүлеге, ул авазларны, аларның кушылмаларын, аваз үзгәрешләрен өйрәнә.

**Фонетик анализ** – сүзне аваз төзелеше ягыннан тикшерү: сүзне транскрипцияләү, авазларга характеристика бирү, сүздәге аваз үзгәрешләрен билгеләү, әйтелеш һәм язылыш арасындагы аермаларны күрсәтү.

**Фонология** – фонетиканың фонемага билгеләмә бирү, теге яки бу телдәге фонемаларның санын һәм составын билгеләү, аларның дифференциаль билгеләрен ачыклау белән шөгыльләнә торган тармагы.

**Фонетик принцип** – ишетелгәнчә язу. Хәзерге татар язуы башлыча шушы принципка корылган.

**Форманта** – авыз һәм тамак резонаторлары аша үткәндә көчәеп киткән тавыш тирбәнешләре. Сузык авазларны аера торган иң мөһим акустик билге. Фонетика өчен аеруча беренче ике форманта әһәмиятле, чөнки алар турыдан-туры авазларның артикуляцияләре белән бәйле булалар.

**Фрикатив** - өрелмәле.

**Хәреф** – бер телнең алфавит составындагы график тамга. Авазларны язуда белдерү өчен хезмәт итә.

**Һәмзә** - бугаз тартыгы.

**Хосусый фонетика** – аерым бер телнең аваз ягын тикшерә.

**Чагыштырма фонетика** – чит һәм туган телдәге авазларны чагыштырып өйрәнә.

**Эксперименталь фонетика** – авазларның ишетелеш һәм әйтелеш ягын төрле техник чаралар, төгәл аппаратура ярдәмендә өйрәнә.

**Энклиза күренеше** – кайбер очракларда бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә килгән ике сүзнең (еш кына ул мөстәкыйль сүз һәм ярдәмлек сүз яки кисәкчә була) берсе басымсыз калырга, һәм шуның исәбенә икенче сүзнең басымы күчәергә мөмкин. Әгәр басымсыз сүз ахырдан килсә – энклитик сүз (энклиза күренеше) була.

**Эпентеза** – фонетик һәм морфонологик шартларга бәйле рәвештә сүздәге ике аваз арасында башлангыч формада булмаган аваз пәйда булу.

Татар телендә алынма сүз кабул иткәндә, әгәр алынма сүзнең башында ике янәшә тартык булса, шулар арасына сузык аваз өстәлү: бревно-бүрәнә.

**Эпитеза** – алынма сүз кабул иткәндә, алынма сүзнең ахырында ике янәшә тартык булса, шуларның ахырына сузык аваз өстәлү: Омск-Омски.

**Ябык иҗек** – тартык авазга тәмамланган иҗек.

**Язу** – график тамгалар системасы ярдәмендә аралашу чарасы.

**Яңгырау тартыклар** – артикуляция вакытында тавыш ярылары тирбәлеп, тавыш өстәлеп әйтелә торган тартык авазлар.

**Тәкъдим ителә торган информацион чыганаклар:**

**а) төп әдәбият**

*Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З.* Хәзерге татар әдәби теле: Югары һәм урта уку йортлары өчен дәреслек. Тулыл. 2 нче басма. – Казан: Мәгариф, 2002. – 235-241 б.

*Сәлимов Х.Х.* Татар теле фонетикасы. – Чаллы: Камаз нәшр., 1993. – 31 б.

*Татар грамматикасы.* Өч томда. Т. I. / Ред. колл. М.З. Зәкиев, Ф.Ә. Ганиев, К.З. Зиннатуллина. – Мәскәү: Инсан; Казан: Фикер, 1998. – 61-151 б.

*Хәкимҗан Ф.* Татар әдәби теле: Фонетика. Югары уку йортлары студентлары өчен. – Тулылан. 2 нче басма. – Казан: ТДГИ, 2001. – 108 б.

*Хисамова Ф.М.* Хәзерге татар теле фонетикасы. Татар филологиясе бүлеге студентлары өчен методик күрсәтмәләр. – Казан, 1987. – 44 б.

**ә) өстәмә әдәбият**

*Абдуллина Р.С.* Алфавитка бәйле орфография һәм орфоэпия мәсьәләләре. – Казан: Тат.кит.нәшр., 2006. – 284 б.

*Абдуллина Р.С.* Стилистика һәм сөйләм культурасы мәсьәләләре. Монография – Яр Чаллы:“КамАЗ” нәшрияты, 1997. – 156 б.

*Алпаров Г.* Шәкли нигездә татар грамматикасы. – Казан, 1925; 2-басма. – Казан, 1926. – 164 б.

*Афлетунов А.Ш.* Фонетика современного татарского языка: Методические указания для студентов заочников по изучению курса и выполнению контрольных работ. – Казань, 1962. – 53 с.

*Байчура Ү.Ш.* Татар теленең кайбер фонетик үзенчәлекләре (Эксперименталь-фонетик мәгълүматлар буенча) // Татар теле һәм әдәбияты мәсьәләләре. – Казан, 1963. –127-140 б.

*Байчура У.Ш.* Звуковой строй татарского языка. – Ч.I. – Казань: Изд-во КУ, 1959. – С. 103-139.

*Байчура У.Ш.* Звуковой строй татарского языка. – Ч.I. – Казань: Изд-во КУ, 1959. – С. 24-61.

*Бакеева Д.Х.* Сопоставительная фонетика английского и татарского языков. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1985. – 141 с.

*Бакиров М.Х.* Закономерности тюркского и татарского стихосложения в свете экспериментальных исследований. – Казань: АКД, 1972. – 298 с.

*Богородицкий В.А.* Введение в татарское языкознание в связи с другими тюркскими языками. Под. ред. чл.-кор. АН СССР проф. Н.К. Дмитриева. – 2-е изд., испр. и доп. – Казань: Татгосиздат, 1953. – 220 с.

*Богородицкий В.А.* Фонетика татарского языка в связи с другими тюркскими языками. – Вестник научн. общ-ва татароведения. - №4. – Казан, 1926. – С. 92-93.

*Богородицкий В.А.* Этюды по татарскому и тюркскому языкознанию. – Казань: Татиздат, 1933. – 156 с.

*Вәлиди Җ.* Татар теленең кагыйдәләре. – Казан, 1918. – 44 б.

*Вәлиева В.С., Саттаров Г.Ф.* Урта мәктәп һәм гимназияләрдә татар телен укыту методикасы. – Казан: “Раннур”, 2000. – 95-143 б.

*Газизов Р.С.* Сопоставительная грамматика татарского и русского языков. – Казань: Таткнигоиздат, 1966. – 368 с.; Казан, 1977. – 271 с.

*Ганиев Ф.А.* Фонетическое словообразование в татарском языке. – Казань: Тат. книж. изд-во, 1973.

*Гиганов И.* Грамматика татарского языка. – СПб., 1801.

*Җәләй Л.* Татар теленең орфоэпик нигезләре. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1953. – 72 б.

*Җәләй Л.* Татар теленең тарихи фонетикасы буенча материаллар. – Казан: Таткнигоиздат, 1954. – 108 б.

*Зиндер Л.Р.* Общая фонетика. – Л.: Изд-во Ленинград. ун-та, 1960; М.: Высшая школа, 1979.

*Исследования по сравнительной грамматике тюркских языков:* Фонетика. Ч. I.– М.: изд. АН СССР, 1955.

*Исхаков Ф.Г.* Об отдельных фонемах татарского языка // Исследования по сравнительной грамматике тюркских языков. – Ч.I. Фонетика. – М.: Изд-во АН СССР, 1955. – С. 239-247.

*Исхаков Ф.Г.* Об отдельных фонемах татарского языка // Исследования по сравнительной грамматике тюркских языков. – Ч.I. Фонетика. – М.: Изд-во АН СССР, 1955. – С. 218-238.

*Исхаков Ф.Г.* Характеристика отдельных гласных современных тюркских языков // Исследования по сравнительной грамматике тюркских языков. – Ч. I. Фонетика. – М.: Изд-во АН СССР, 1955. – С. 53-114.

*Камчатнов, А.* М. Введение в языкознание [Электронный ресурс] : учеб. пособие / А. М. Камчатнов, Н. А. Николина. - 10-е изд., стереотип. - М. : Флинта:Наука, 2011. - 232 с. // http://znanium.com/bookread.php?book=405795

*Курбатов Х.Р.* Орфоэпия // Хәзерге татар әдәби теле: Лексика, фонетика, орфоэпия, графика һәм орфография, морфология: Югары уку йорты студ. һәм урта мәктәп укытучылары өчен. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1965. – 133-153 б.

*Лингвистические задачи*: Учебное пособие / Б.Ю. Норман. - М.: Флинта: Наука, 2006. - 272 с. // http://znanium.com/bookread.php?book=320773

*Махмудов Г.* Практическое руководство к изучению татарского языка. – Казань, 1858.

*Миргалимова З.Ф., Сәләхетдинова З.Ф.* Татар теле: Фонетика. Югары уку йорты студентлары өчен уку-укыту кулланмасы. – Казан: Редакционно-издательский центр, 2011. – 119 б.

*Насыйри К.* Әнмүзәҗ. – Казан, 1895; Казан, 1975. – 213 б.

*Насыри К.* Краткая татарская грамматика. – Казань, 1860.

*Низамов И.М.* Уем – тел очында: Сөйләм һәм массакүләм аралашу. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1995. – 287 б.

*Ногман М.* Татар тел культурасы тарихыннан // Совет мәктәбе – 1957. – №7. – 100-109 б.

*Нуриев Р.* Сәнгатьле уку: Методик ярдәмлек. – Казан: Мастер Лайн, 2000. – 152 б.

*Нуриев Р.* Татар сәхнә сөйләме. – Казан: Мирас. – 1998.

*Нуриева Ф.Ш.* Атрибуция языка письменных памятников Золотоордынского периода. – Астана: “Кантана Пресс”, 2011. – 180 с.

*Сабиров К.С.* Фонетик ысул белән сүз ясалышы // Совет мәктәбе. – 1970, – №5 – 35 б.

*Сагдеева Ф.К.* Проблемы культуры татарской речи в условиях активного двуязычия. – Казан:“ Фикер”, 2003. – 159 с.

*Сайхунов М.Р.* Ритмо-темпоральные характеристики татарского языка в плане автоматического синтеза в речи: Автореф. дис. …канд. филол. наук. – Казань, 2010. – 26 с.

*Салимов Х.Х.* Спектральный анализ татарских гласных: Автореф. дис. ...канд. филол. наук. – Казань, 1975. – 24 с.

*Саттаров Г.Ф.* V-VIII класс укучыларының тел культурасын үстерү. - Казан: КДУ нәшр, 1962.

*Саттаров Г.Ф.* Алынма сузыкларны өйрәнү // Совет мәктәбе. – 1966. - №10. – 32-35 б.

*Саттаров Г.Ф.* Мәктәптә тел культурасы. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1965. – 151 б.

*Саттаров Г.Ф.* Сопоставительный анализ звукового состава татарского литературного языка и диалектов // Вопросы татарского языкознания. – 1965. – С. 120-146.

*Саттаров Г.Ф.* Фонетика укытуга карата // Совет мәктәбе. – 1964. – №9. – 37-39 б.

*Сафиуллин Ф.С.* Тел гыйлеменә кереш. – Казан: “ТаРИХ”, 2001. – 37-104 б.

*Сафиуллина Ф.С.* Хәзерге татар әдәби теле фонетикасы: Күнегүләр җыентыгы. – Казан, 1968. – 43 б.

*Сафиуллина Ф.С.* Хәзерге татар әдәби теле: Күнегүләр. Югары һәм урта уку йортлары өчен тулыландырылган икенче басма. – Казан: Мәгариф, 2002. – 5-27 б.

*Сәгыйтов М.А.* Фонология, аның идея һәм проблемалары. – Казан: Казан пед. инс-ты нәшр., 1972. – 120 б.

*Сәлимов Х.Х.* Хәзерге татар теле фонетикасы. Методик күрсәтмәләр. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1978. – 65 б.

*Сәлимов Х.Х., Гыйзәтдинова Г.Х.* Татар теленең орфоэпик сүзлеге. – Чаллы: Камаз, 1995. –127 б.

*Сөнгатов Г.М.* Татар диалектларының фонетикасы: Татар филологиясе һәм тарихы факультеты студентлары өчен уку ярдәмлеге. – Казан: КГУ, 2000. – 44 б.

*Сөнгатов Г.М.* Татар теленең фонетик закончалыклары: Теоретик мәгълүмат, күнегүләр һәм биремнәр. – Казан: КГУ, 2001.–53б.

*Сунгатов Г.М.* Фонетическая система заболотного говора тоболо-иртышского диалекта сибирских татар (экспериментально – фонетическое исследование): Автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Казань, 1991. – 23.

*Сунгатов Г.М.* Экспериментально-фонетическое исследование татарской диалектной речи. – Казань: Сиддхи-секьюрити, 2002. – 108 с.

*Теория языка*. Вводный курс: Учебное пособие / А. А. Горбачевский. - М.: Флинта: Наука, 2011. - 280 с. // http://znanium.com/bookread.php?book=447873

*Фасеев Ф.С.* Вокализм татарского языка в синхронии и диахронии // К формированию языка татар Поволжья и Приуралья. – Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова, 1985. – С. 99-109.

*Хаков В.Х.* Татар әдәби теле тарихы. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1993. – 325 б.

*Хаков В.Х.* Тел тарих көзгесе (Татар әдәби теленең үсеш тарихыннан). – Казан: Татар. Кит. нәшр., 2003. – 295 б.

*Халфин И.* Азбука и грамматика татарского языка. – Казань, 1809. – 106с.

*Халфин С.* Азбука татарского языка с обстоятельным описанием букв и складов. М., 1778; М.: Издательство МГУ; Издательство КГТУ, 1996. – 60 с.

*Хангилдин В.Н.* Татар теленең орфоэпик нормалары мәсьәләсе / Совет мәктәбе – 1941. - №5. – 15-17 б.

*Харисова Ч.М.* Татар теле: Теория, күнегүләр, тестлар. – Казан: “Мәгариф”, 2006. – 7-30 б.

*Хәзерге татар әдәби теле:* Лексика, фонетика, орфоэпия, графика һәм орфография, морфология: Югары уку йорты студ. һәм урта мәктәп укытучылары өчен. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1965. – 96-176 б.

*Хәйруллина А.Х.* Дөрес сөйләргә өйрәнегез. – Казан: “Казан” нәшр., 1992. – 96 б.

*Хәкимҗан Ф.* Татар әдәби теле фонетикасы: Күнегүләр җыентыгы. – 2000. – 28 б.

*Шакирова Р.Ф.* Хәзерге татар теле фонетикасына кереш. – Казан: Таткнигоиздат, 1954. – 57-71 б.

*Шакирова Р.Ф.* Хәзерге татар теле фонетикасына кереш. – Казан: Таткнигоиздат, 1954. – 104 б.

*Шараф Г.* Палятограммы звуков татарского языка сравнительно с русскими. – Казань, 1927. – 40 с.

*Шараф Г.* Сонорная длительность татарских гласных // Вестник научного общества татароведения. - Казань, 1928. - №8. – С.180-265.

*Щербак А.М.* Сравнительная фонетика тюркских языков. – Л.: Наука, 1970. – 204 с.

*Юсупов Р.А.* Әдәп башы – тел: Икетеллелек шартларында дөрес сөйләм мәсьәләләре. – Казан: КДПУ, 2000. – 218 б.

*Юсупов Р.А.* Икетеллелек һәм сөйләм культурасы. – Казан: Тат.кит.нәшр., 2003. – 223 б.

*Юсупов Р.А*. Инсафлының теле саф (Дөрес сөйләм турында иншалар). – Казан: КГПИ, 1993. – 162 б.

*Юсупов Р.А.* Укучыларда сөйләм культурасы тәрбияләү / Р.А. Юсупов. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1983. – 137 б.

*Юсупов Ф.Ю.* Җирле сөйләш шартларында фонетика укыту. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1977. – 165 б.

*Юсупов Ф.Ю.* Җирле сөйләш шартларында фонетика укыту. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1977. – 165 б.

*Юсупов Ф.Ю.* Көньяк Урал һәм Урал арты сөйләшләре: Чиләбе һәм Курган өлкәләрендәге татар сөйләшләренең фонетик үзенчәлекләре. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1979. – 184 б.

*Яфаров Л.* Татар теле үсештә. – Казан: Татгосиздат, 1955. – 130 б.

*Яфаров Л.И.* Татар теле фонетикасының кайбер закончалыклы тенденцияләре: Филол. фән. канд. ... дисс. – Казан, 1955. – 264 б.

*Radloff W.W.* Phonetik der nordlichen Turksprachen. – Leipzig, 1883.

**Тәкъдим ителә торган электрон ресурслар:**

www.wikipedia.ru  Универсальная энциклопедия «Википедия»

www.ksu.ruЭлектронная библиотека и материалы сайта КПФУ

www.slovari.ru  Электронные словари

**“Татар теле фонетикасы” курсыннан имтихан сораулары**

1. Тел белеменең аерым тармагы буларак фонетика. Башка тел фәннәре арасындагы урыны, өйрәнү объекты.

2. Татар теле фонетикасын өйрәнүнең кыскача тарихы һәм хәзерге көндә өйрәнүнең торышы.

3. Фонетика фәненең методлары. Татар фонетикасында эксперименталь методлар куллану.

4. Аваз һәм фонема. Телдә фонемаларны аерып чыгару принциплары. Фонема вариантлары, әлеге мәсьәләдә татар тел белемендә карашлар

5. Сузык һәм тартык фонемалар, алар арасындагы акустик һәм артикуляцион аермалар, ясалыш үзенчәлекләре.

6. Сузык фонемалар. Сузык фонемаларның саны, составы турында татар тел белемендәге карашлар. Сузыкларны төркемләү принциплары.

7. Татар телендә тартык фонемалар саны һәм составы. Бу мәсьәләдә төрле карашлар. Тартыкларны төркемләү принциплары.

8. Ясалу урыны буенча тартык авазларны төркемләү.

9. Татар телендә фарингаль һәм ларингаль тартыклар. Татар әдәби телендә һәм диалектларда хәмзә авазының кулланылышы һәм язуда бирелеше.

10. Резонатор урынына карап тартыкларны төркемләү.

11. Ясалыш ысулына карап тартыкларны төркемләү.

12. Тавыш һәм шауның катнашуына карап тартыкларны төркемләү.

13. Татар теле фонемаларының телдә кулланылу ешлыклары. Фонемаларның янәшәлек күрсәткечләре.

14. Фонетик транскрипция. Транслитерация.

15. Татар телендә дифтонглар, аларның төрләре. Трифтонглар.

16. Төшерелмә дифтонглар, мисаллар китерергә.

17. Күтәрелмә дифтонглар. Мисаллар китерергә.

18. Авазларның комбинатор үзгәрешләре. Сингармонизм законы, аның төрләре.

19. Сингармоник парлар. Аларның ике төре.

20. Сингармоник парларга мисаллар китерергә.

21. Авазларның комбинатор үзгәрешләре. Аккомодация күренеше (тартыкларның сузыкларга тәэсире).

22. Аккомодация күренешенең бер төре буларак сузыкларның тартыкларга тәэсире. Авазлар чиратлашу.

23. Аккомодация күренешенә мисаллар китерегез.

24. Тартыкларның комбинатор үзгәрешләре. Ассимиляция һәм диссимиляция күренеше. Аның төрләре.

25. Диалектлардан диссимиляция күренешенә мисаллар китерегез.

26. Акустик ассимиляциягә мисаллар китерегез.

27. Сузык авазлар өлкәсендәге позицион үзгәрешләр (редукция, протеза, эпентеза).

28. Тартык авазлар өлкәсендәге позицион закончалыклар (сүз башы, сүз ахыры закончалыгы).

29. Тартыкларның яңгыраулыкта-саңгыраулыкта охшашланулары. Мисаллар китерергә.

30. Ясалу урыны буенча тартыклар охшашлануга мисаллар китерегез.

31. Татар телендә элизия күренеше.

32. Татар орфоэпиясе, аның бүгенге көндә әһәмияте. Татар орфоэпиясенең кыен очраклары.

33. Татар телендә сузыклар орфоэпиясе.

34. Татар телендә тартыклар орфоэпиясе.

35. Хәзерге вакытта татар орфоэпиясен бозып сөйләү очраклары, аның сәбәпләре.

36. Сингармонизм күренешенә бәйле орфографик һәм орфоэпик кагыйдәләр.

37. Орфографиянең предметы, бурычлары һәм әһәмияте. Гарәп, латин, кириллица алфавитларына нигезләнгән орфографияләр, аларның аермалы яклары.

38. Хәзерге татар орфографиясе һәм аның төп принциплары.

39. Морфологик принцип буенча языла торган сүзләргә мисаллар китерегез.

40. Алгы рәт сузыклары чолганышында увуляр *к*, *г* авазларының язуда бирелешен аңлатырга.

41. Хәзерге татар язуында *ъ* һәм *ь* билгеләре нинди вазыйфа үти?

42. Берничә авазга билге булып йөрүче хәрефләр.

43. Татар телендә әйтелеш белән язылыш арасында зур аерма булган очраклар.

44. Татар язуы тарихы. Хәреф һәм алфавит реформалары.

45. Татар язуында гарәп графикасы. Имла төзәтү.

46. Хәзерге татар графикасы. Аның телдәге авазларны чагылдыру үзенчәлекләре.

47. Сүзләрне кушып, сызыкча аша, аерып язу. Сүз кисәкләрен юлдан-юлга күчерү.

48. Татар теленең просодикасы, аның компонентлары.

49. Татар сөйләменең интонациясе: аның состав өлешләре, әһәмияте, роле.

50. Интонациянең бер элементы буларак татар тел белемендә басым. Аның төрләре.

51. Сүз басымы: аның фонетик табигате, урыны, мәгънәви роле. Татар телендә сүз басымының урыны.

52. Татар телендә сүз басымы мәсьәләсе.

53. Логик басым. Аның фонологик роле. Эмфатик басым.

54. Татар теленең иҗек төзелеше. Татар һәм төрки телләрдә иҗек калыплары.

55. Г.Алпаровның татар теле фонетикасы өлкәсендәге эшчәнлеге.

56. Л. Җәләйнең татар фонетикасын өйрәнүгә багышланган хезмәтләре.

57. Каюм Насыйриның татар фонетикасы өлкәсендәге эшчәнлеге.

58. XX гасырның икенче яртысында татар фонетикасының үсеше.

**Белемнәрне гомумиләштереп кабатлау өчен тестлар**

I вариант

1. “*Әнмүзәҗ*”(1895) хезмәтенең авторы – ….. .

2. Телнең аваз составын, фонетик закончалыкларны, просодик элементларны өйрәнә торган фән ..... дип атала.

3. Сөйләмнең таркалмый торган иң кечкенә берәмлеге – ..... .

4. Татар теленең үз сузык авазларының саны – ..... .

5. Алгы рәт, урта күтәрелеш, иренләшкән кыска сузык аваз – ..... .

6. Йомык, тел алды, саңгырау, шаулы, авыз авазы ..... .

7. Йомык, тел алды, яңгырау, шаулы, авыз авазы ..... .

8. Татар телендә тартык фонемаларның саны – ..... .

9. Авазны әйтүгә хәзерлек ..... дип атала.

10. Ике сүзнең беренчесе сузык авазга тәмамланып, икенчесе сузык авазга башланып, бер басым астында әйтелгәндә барлыкка килә торган үзгәрешләрне ..... күренеше диләр.

11. Этимологик яктан бер үк тамырга кайтып кала торган калын һәм нечкә әйтелешле сүзләр ..... дип атала.

12. Комбинатор аваз үзгәрешләре авазларның бер-берсенә ..... нәтиҗәсендә барлыкка киләләр.

13. Позицион аваз үзгәрешләре авазның сүздәге ..... мөнәсәбәтле рәвештә барлыкка киләләр.

14. Борын авазларына тәмамланган сүзләргә борын тартыкларыннан башланган кушымчалар ялганса, ..... ассимиляциясе барлыкка килә.

15. Сүз эчендә кайсы урында килүләренә карап, шулай ук иҗекнең характерына һәм басым төшү-төшмәүгә бәйле рәвештә сөйләм эчендә

авазларның төрле үзгәрешләре барлыкка килергә мөмкин. Мондый аваз үзгәрешләре ..... үзгәрешләр дип атала.

16. Татар телендә сузыкларның ..... тәэсире көчлерәк.

17. *Чишмә-тишмә, директор-дилектыр, шешә-чэшә* сүзләре – ..... күренешенә карый.

18. Сүз азагында н авазы килеп, кушымчалар г, ғ яки к, қ авазларына башланса н авазы ..... булып әйтелә.

19. Алынма сүзләрдә мәгънәгә һәм этимологиягә бәйләнеше булмаган сузык сүз башында килсә ..... күренеше дип атала.

20. Сөйләмнең ритмик-мелодик ягы буларак мәгънәле кисәкләрен аеру, синтаксик мәгънәләр белдерү, сөйләмгә субъектив мөнәсәбәт белдерү өчен хезмәт итә торган аваз чаралары җыелмасы ..... дип атала.

II вариант

1. “*Звуковой строй татарского языка*” (1959) дигән хезмәтнең авторы – ….. .

2. Конкрет бер телдәге авазлар системасының төрле чорлар дәвамындагы үсешен ..... тикшерә.

3. Телдәге сүзләрне, морфемаларны төзи һәм аларны бер-берсеннән аеру өчен хезмәт итә торган иң кечкенә аваз берәмлеге – ..... дип атала.

4. Татар телендә алынма сузык авазларның саны – ..... .

5. Арткы рәт, түбән күтәрелеш, иренләшмәгән озын сузык аваз – ... .

6. Калтыраулы, тел алды, яңгырау, авыз авазы ..... .

7. Өрелмәле, ирен-ирен, яңгырау, авыз авазы ..... .

8. Шаудан гына торган тартыклар ..... тартыклар дип атала.

9. Авазны әйтү моменты ..... дип атала.

10. Бер сүз эчендә сузык авазлар охшашлану – ..... күренеше дип атала.

11. Иренләшкән [о], [ө] сузыкларының үзләреннән соң килгән [ы], [е] сузыкларын иренләштерүләренә ..... дип әйтәбез.

12. Сингармонизм күренеше бары тик ….. телләр өчен генә хас.

13. Аккомодация күренеше нинди авазлар арасында булуына карап ..... һәм ..... аккомодациясенә бүленә.

14. Иренләшкән сузыклар янында тартыклар беркадәр ..... әйтелә.

15. Төрле характердагы авазларның бер-берсенә җайлануы, сузыкларның тартыкларга, тартыкларның сузыкларга тәэсире нәтиҗәсендә барлыкка килә торган аваз үзгәрешләренә ..... дип әйтәләр.

16. Язуда кулланыла торган хәрефләрнең билгеле бер тәртиптә урнаштырып бирелүе ..... дип атала.

17. Тартыкларның охшашсызлану күренеше – ..... дип атала.

18. Интонация ике аспектта карала – ..... һәм ..... .

19. Кайбер очракларда бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә килгән ике сүзнең берсе басымсыз калырга, һәм шуның исәбенә икенче сүзнең басымы күчәергә мөмкин. Әгәр басымсыз сүз ахырдан килсә – ..... була.

20. Сүздә нинди авазлар әйтелә, шуларның үз график билгеләрен куеп язу принцибы – ..... принцип.